ШАУ-ШУЛЫ ҖАНИСӘП

Ни өчен кайбер төбәкләрдә татарлар саны коточкыч дәрәҗәдә кимегән?

> 5

СӨТ БӘЯСЕ

«ВТ» хәбәрчесе Апас районының Олы Бакырчы авылына барып кайтты

> 6

РАВИЛ ШӘРӘФИ:

«Халыкны тәрбияләргә кирәкми, бозмаска кирәк»

> 18–19

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 24 (28991) | Җомга | 17 февраль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

shutterstock.com

ҮЧТЕКИ-ҮЧТЕКИ, АКЧА САНЫЙ КЕЧТЕКИ

БАЛА ТӘРБИЯЛӘҮ КҮПМЕГӘ ТӨШӘ?

Белмәсәгез белегез: баланы туганнан алып өч яшькә кадәр үстерү өчен аз да түгел, күп тә түгел, 1 миллион 370 мең сум акча кирәк. Россиядә яшәүче әниләрнең исәп-хисабы бу. Баланы акча бизмәненә салып үлчәү белән килешмәүчеләр дә күп, билгеле. Тик тормыш булгач, ансыз да булмый. Бала хакы күпме? Бала үстерүче гаиләләргә дәүләт ярдәме җитәме? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга җавап эзләде.

> 17

Ишетми калмагыз

Казанның Идел буе районында берничә яңа урамга исем биргәннәр. Шуларның дүртесе «Лесная поляна» торак массивында урнашкан. Яңа урамнар Диләрә Тумашева (Россия һәм Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Фәннәр академиясе академигы, филология фәннәре докторы, тел белгече), Лена Шагыйрьҗан (Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, халык шагыйре, публицист, тәрҗемәче), Тәүфикъ Әйди (ТАССР-ның атказанган мәдәният хезмәткәре, язучы, публицист, тәрҗемәче), Иван Харитонов (Россия мәгърифәтчесе, китап нәшер итүче, XX гасыр башының танылган типографы) исемнәрен йөртәчәк. Яңа микрорайонда тагын ике урам төзелеп килә. Берсенең исеме – «Тирәкле», икенчесенеке «Кызыл Ромашка» булачак.

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан буенча Баш идарәсе тикшерүчеләре узган елда 1061 җинаять эше кузгаткан. Татарстан Рәисе матбугат хезмәте хәбәренә караганда, күпчелеге – 98 проценты – Россия Җинаять кодексының 157 статьясына («Алимент түләүдән качу») туры килә.

Баш идарә җитәкчесе Әнвәр Закиров әйтүенчә, 2022 елда ведомство тикшерүчеләре карамагында барлыгы 1206 җинаять эше булган. Алдагы елдагыга караганда 190га кимрәк бу. 988ен тикшерү тәгәлләнгән. Алар, гаепләү акты белән, судка җибәрелгән.

Исегезгә төшерәбез: 2022 елда Татарстанда суд приставлары бурычлыларның 11359 мөлкәтенә арест салган. Бу – алдагы елдагыга караганда (878) 2,5 меңгә күбрәк.

Узган тәүлектә Татарстанда коронавирус инфекциясен йоктыруның 110 очрагы ачыкланган. 71 сырхау хастаханәгә озатылган. Шул рәвешле, республикада өченче көн рәттән чирләүчеләр саны арта: моңа кадәр 99 һәм 101 очрак теркәлгән. Республикада инде узган елның 18 декабреннән бирле (ул көнне 111 кеше инфекция иярткән) чирләүчеләр шуның кадәр күп санда теркәлмәгән булган.

Савыгучылар да арткан: алдагы көнне – 78, соңгы тәүлектә – 127 кеше. Шөкер, яңа үлем-китем очраклары юк. Татарстанда соңгы тапкыр коронавируска бәйле үлем 20 гыйнварда теркәлгән.

Татарстан Гидрометеоүзәгеннән хәбәр ителгәнчә, ял көннәрендә 20 градуска кадәр суыта. Кайбер районнарда томан төшәргә мөмкин. Шимбә, якшәмбе – 18 һәм 19 февральдә көндез термометрның терекөмеш баганасы –6…–12 градус күрсәтәчәк. Төнлә һава температурасы –11…–16, урыны белән –20 градуска кадәр төшәчәк.

Синоптикларның башлангыч фаразына караганда, киләсе атна башы – 20–21 февральдә болытлы һава, аз гына кар явачак. 20 февральдә көндезге температура –4…–9 градус чикләрендә тирбәлсә, төнлә –9…–14 градус булачак. Сишәмбе – 21 февральдә көндез –7…–12, төнлә –12…– 17.

Районнарда ни хәлләр?

Азнакай

Район мәчетләре хәзрәтләре актив тормыш белән яши. Бу атнада алар чаңгы базасына җыелды. Олы яшьтә дип тормадылар, барысы да старт юлына басты. Спорт сөюче имамнарны район советы аппараты җитәкчесе Айдар Хәлиуллин сәламләде. «Өлкән буын һәр эштә актив катнаша. Сез яшьләргә үрнәк булып торырлык», – диде ул. Район мөхтәсибе Азат хәзрәт Талибуллин әйтүенчә, имамнар катнашында мондый чаралар даими уздырылып тора. «Җәй көннәрендә балык тоту ярышлары уздырабыз, экстремизмга каршы айлык кысасында үткән велойөрештә дә актив катнашабыз», – диде ул.
(«Маяк»)

Әтнә

Габдулла Тукай исемендәге Әтнә татар дәүләт театры 17 февральдән балалар һәм үсмерләр арасында республика күләмендә драматургия конкурсы игълан итә. Конкурста татар телендә язылган оригиналь пьесалар катнаша. Әлеге бәйге Гомәр Мәрданов исемендәге театр фестивале кысасында үтә. Конкурста 18 яшькә кадәрге балалар һәм үсмерләр катнаша ала. Беренче урын алучыга – 30 мең сум, икенчегә – 20 мең сум, өченчегә 10 мең сум премия вәгъдә итәләр. Гаризалар 17 июньгә кадәр кабул ителә. Җиңүчеләрне игълан итү һәм бүләкләү тантанасы 17 ноябрьдә Яңа Кырлайда Габдулла Тукай әдәби-мемориаль музей комплексында узачак.
(«Әтнә таңы»)

Зәй

Зәйдә яшәүче Бөек Ватан сугышы ветераны Анна Моисеевага 100 яшь тулды. Аны тәбрикләргә килгән яшьләр, мәктәп укучылары, район башлыгы Разиф Кәримов, район, ул хезмәт куйган оешмалар җитәкчеләре, хәрбиләр – барысы да мөхтәрәм ветеранга җылы теләкләрен җиткерделәр. Анна Ивановна 1923 елда Зәй районының Подгорный бистәсендә гаиләдә тугызынчы – төпчек бала булып дөньяга килгән. Бөек Ватан сугышы башлангач, ул шәфкать туташлары курсын тәмамлый. 1942 елның июль аенда Зәй хәрби комиссариатына иптәш кызлары белән бергәләп фронтка алуларын сорап килә. Аларны Беренче Белоруссия фронтының 61 нче армиясе 473 нче күчмә кыр хирургия госпиталенә җибәрәләр. Анна Ивановна биредә 1945 елга кадәр кече медицина хезмәте сержанты буларак фронт юлы үтеп, Берлинга кадәр барып җитә. Сугыштан соң ул район хастаханәсендә шәфкать туташы булып 40 ел хезмәт куя.
(«Зәй офыклары»)

Түбән Кама

13 февральдә Түбән Камада Терендез бәйрәме узды. Чараны Халыклар дуслыгы йорты янында үткәрделәр. Бәйрәм учак янында милли җырлар һәм биюләр белән үрелеп барды. Әрмәнстанда Терендез бәйрәменең барлыкка килү тарихы мәҗүсиләр чорына барып тоташа. Кешеләр, утның көче кышның салкынлыгын сындырырга һәм кырларны уңышлы итәргә булыша, дип саныйлар. «Мондый чараны ел саен уздырабыз. Барыгызны да котлыйм!» – диде Халыклар дуслыгы йорты җитәкчесе Васил Хафизов. Кунаклар традицион кочари биюенә кушылды. Шулай ук бәйрәмдә учак аша да сикерделәр. Тантанага килүчеләрне шашлык һәм әрмән чәе белән сыйладылар.
(e-nkama.ru)

КИЛЕП КҮРСЕННӘР

«Сез башкалардан аерылып торасыз...» Чирмешән районы советы утырышында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов үзәкне тәртипкә китерергә кушты. Чарада авыл хуҗалыгына, социаль тармакка кагылышлы бурычлар да шактый күп яңгырады. «Тотрыклы» дип бәяләнгән районда эш җитәрлек, кыскасы.

tatarstan.ru

Узган ел йомгаклары турында район башлыгы Рамил Айбәтов сөйләде. Аның әйтүенчә, былтыр Чирмешәндә 3,4 миллион тонна нефть чыгарганнар. Бу Татарстан буенча гомуми күрсәткечнең 10 процентын тәшкил итә.

– Чирмешәндә яшәүче 663 кеше нефть тармагында эшли, – диде район башлыгы.

Районның төп нигезен дә сәнәгать тармагы тәшкил итә. Узган ел Чирмешәндә 32,3 миллиард сумлык тулай территориаль продукт җитештерсәләр, аның 90 проценты диярлек сәнәгать тармагына, аерым алганда нефть чыгаруга туры килгән. Эчке тулай продукт күрсәткече буенча район – Татарстан күләмендә 18 нче урында. Ә төяп озатылган товарлар һәм хезмәтләр күләме буенча исә 19 нчы баскычта тора.

1 гыйнварга алынган мәгълүматларга караганда Чирмешәндә эшсезлек дәрәҗәсе 0,34 процент тәшкил иткән. Ягъни 32 кеше эшсез буларак исәптә тора. Шул ук вакытта 58 эш урыны буш.

– Бигрәк тә ветеринария табибы, баш агроном, тракторчы, машина йөртүче һөнәрләренә ихтыяҗ зур, – диде Рамил Айбәтов.

Халыкны эш белән тәэмин итү турында сөйләгәндә, Рөстәм Миңнеханов кече һәм урта бизнесны үстерүгә дә игътибарны юнәлтте.

– Бу өлкәдә мәшгуль булган җирле халык саны буенча сез – 37 нче урында, – диде Рәис.

Ул терлекчелек һәм үсемлекчелек кебек тармакларны да күз уңында тотарга киңәш итте. Аерым алганда, сөт җитештерүне арттырырга, тагын да күбрәк уңыш алу өчен, ашламалар кулланырга кирәклеген искәртте Рөстәм Миңнеханов.

Эшне исә үзәктән үк башларга туры киләчәк.

– Район үзәген тәртипкә китерергә кирәк. Сезнең район башкалардан аерылып тора. Көч куюны таләп итүче объектлар да җитәрлек. Бирегә безнең архитектура десантын җибәрергә кирәк. Килсеннәр, карасыннар, киңәшләрен һәм тәкъдимнәрен җиткерсеннәр. Район үзәге матур булырга тиеш дип саныйм, – диде республика башлыгы.

Сессия утырышында демография, нефтькә бәйле булмаган тармакларда хезмәт хакларын күтәрү кебек мәсьәләләрне дә күтәрделәр.

– Гомумән алганда, район тотрыклы, үсеш өчен юнәлешләр күп. Агросәнәгать комплексы, шәхси хуҗалыклар буенча эшне көчәйтергә кирәк. Ярлылыкка каршы көрәш һәм демография мәсьәләсе дә көн тәртибендә торырга тиеш, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Чирмешәндә республика башлыгы солдат Евгений Зоринның гаиләсе белән дә очрашты. Евгений Зорин сугышчан бурычын үтәгәндә батырларча һәлак булган. Ул контракт буенча хәрби хезмәткә 2021 елның июнендә алынган. Россия Президенты Указы белән Евгений Зорин хәрби бурычын үтәгәндә күрсәткән батырлыгы, каһарманлыгы һәм фидакарьлеге өчен Батырлык ордены белән бүләкләнгән. Бүләкне аның тол калган хатыны Людмила Зоринага тапшырдылар.

Районда Рәис «Хан-Су» шифалы су тутыру цехы, шулай ук, Советлар Союзы Герое Иван Конев исемендәге Чирмешән кадетлар интернат мәктәбендә дә булды.

ЭШЛИСЕ ЭШЛӘР БИХИСАП

Узган ел Спас районында 830 меңнән артык турист кунак булып киткән. Кырлардан рекордлы күләмдә уңыш җыеп алганнар. Аның каравы сөт һәм ит җитештерү кимегән. Социаль-икътисадый үсеш рейтингында исә район – 40 нчы урында гына. Район советының хисап сессиясендә Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да катнашты.

Җыелыш алдыннан парламент җитәкчесен Болгар 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенә алып бардылар. 50 ел элек төзелгән өч катлы бинада былтыр капиталь ремонт үткәрелгән. Фәрит Мөхәммәтшин бишенче сыйныф укучылары өчен парламент дәресе уздырды. Укучылар Татарстан халыкларының бердәмлеге, мәдәнияте һәм традицияләре турында фикер алыштылар. Дәүләт Советы Рәисе Геройлар аллеясында Әфганстаннан совет гаскәрләрен чыгаруның 34 еллыгына багышланган тантаналы митингта да катнашты.

Чыгыш ясаганда район башлыгы Фәргать Мөхәммәтов узган елда тулай территориаль продуктның 7,4 млрд сум тәшкил иткәнен әйтте, ә бу 2021 ел дәрәҗәсеннән 8,5 процентка күбрәк икән. Кырлардан 177 мең тоннадан артык уңыш җыеп алынган. Әмма терлекләрнең баш саны, сөт һәм ит җитештерү кимегән. «Гомумән терлекчелек тармагында без әле начар эшлибез. Тармакны үстерүдә дәүләт күрсәтә торган ярдәм программалары аз кулланыла», – диде ул.

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, районда 2022 елга билгеләнгән барлык проектларны һәм программаларны гамәлгә ашырганнар, республика икътисадына саллы өлеш керткәннәр. Әмма социаль-икътисадый үсеш рейтингында Спас районы, бер ел эчендә ике позициягә төшеп, 40 нчы урынны били. Район торак тапшыру буенча 44 нче урында гына тора, узган ел нибары 4,65 мең кв. м торак тапшырылган. «Эшлисе эшләр бар», – диде Фәрит Мөхәммәтшин. Парламент башлыгы әйтүенчә, терлекчелекне үстерү, район бюджетының керем базасын тулыландыру, Болгарны туристлар үзәге буларак төзекләндерү, кунакчыллык күрсәтү кебек юнәлешләргә игътибарны арттырырга кирәк.

Дәүләт Советы Рәисе шулай ук районда аерылышучылар саны күп булуга да игътибар итте. Узган ел 98 гаилә теркәлгән, ә 72се таркалган. Республикада халык саны артуга карамастан, районда халык саны да кимегән. «Вазгыять сәбәпләрен ачыкларга, үсешнең яңа юнәлешләрен табарга һәм кешеләрнең тормыш сыйфатын яхшыртырга – җирле хакимиятнең бурычы әнә шул», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Депутатлар киләсе атнада җыела

Алтынчы чакырылыш Дәүләт Советының кырык беренче утырышы 22 февральдә үткәреләчәк. Татарстан парламентының Президиум утырышында шундый карар кабул ителде.

Депутатлар 23 мәсьәләне, шул исәптән 10 республика законы проектын, 4 федераль закон проектын һәм Чиләбе өлкәсенең закон инициативасын карап тикшерергә ниятли.

Кырык беренче утырышта шулай ук Татарстан буенча эчке эшләр министры полициянең узган елдагы эшчәнлеге турында хисап тотачак. Татарстанда Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 2022 елдагы эшчәнлеге турында чыгышы һәм 2021–2030 елларга Казан (Идел буе) федераль университетын үстерү программасын тормышка ашыру турында хисаплары да тыңланачак. «Хөкүмәт сәгате» кысасында исә Татарстан дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин республикада Цифрлаштыру елын үткәрү турында сөйләячәк.

Утырышның көн тәртибенә Дәүләт Советының балалар оешмаларында педагогик эшчәнлек алып баручыларга вакытыннан алда пенсиягә чыгу хокукы биргән вазыйфалар һәм учреждениеләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында Россия Хөкүмәте Рәисе Михаил Мишустинга мөрәҗәгате кертелгән. Дәүләт Советы депутатлары вакытыннан алда пенсиягә чыгу хокукына ия педагоглар исемлеген киңәйтергә: аңа мәктәп директорларының тәрбия һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән эшләү буенча киңәшчеләрен өстәргә, балалар бакчаларында туган телләргә, чит телләргә өйрәтүче тәрбиячеләргә дә шундый хокук бирергә тәкъдим итә.

ТЫНЫЧЛЫК ӨЧЕН ТЫРЫШЛЫК

Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы уңаеннан Татарстан Халыклар дуслыгы йортының «Милли бердәмлек көннәре» проекты тормышка ашырыла башлаячак. Авылларга чыгып, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне өйрәнмәкчеләр. Татарстан халыклары ассамблеясы советының узган елгы эшчәнлегенә багышланган утырышта киләчәккә планнар турында да сөйләштеләр.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясы Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин махсус хәрби операцияне зур сынау дип атады. Хәрбиләргә, илнең яңа төбәкләрендә яшәүчеләргә бөтен халык ярдәм күрсәтә. Бу көннәрдә Төркия һәм Сүриядә ярдәм көтәләр. Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, бу эштән Татарстан халыклары ассамблеясы да читтә калмады.

Ассамблеяның 2023 елга планнары турында сөйләгәндә, Фәрит Мөхәммәтшин милли һәм дини, рухи һәм мәдәни өлкәләрдәге проблемалар һәм бурычларның кимемәвен әйтте. Шуңа күрә бу юнәлештә эшне бердәм һәм системалы рәвештә дәвам иттерергә чакырды.

– Безнең уңышның нигезе – гражданнар җәмгыятенең актив ярдәме белән Татарстан хакимиятенең барлык тармакларының үзара килешеп эшләвендә, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Ассамблеяның башкарма комитеты җитәкчесе Константин Яковлев белдергәнчә, оешма милли традицияләрне, мәдәниятне, телләрне саклау һәм үстерү буенча мөһим эш башкара. Төп юнәлешләрнең берсе – мигрантларны үзебезнең җирлеккә җайлаштыру. Миграция хезмәте мәгълүматларына караганда, 2022 елда Татарстанда 330 меңнән артык чит ил кешесе миграция исәбенә куелган. Бу 2021 ел күрсәткечләреннән 26 процентка күбрәк. Хәзерге вакытта ассамблея составында 36 милләтнең 258 җирле иҗтимагый оешмасы, 14 Халыклар дуслыгы йорты, 2 филиал һәм 34 вәкиллек бар. Узган елда тагын өч вәкиллек ачылган. Районнарда, бигрәк тә зур шәһәрләрдә бүлекләрнең эше активлашкан.

Татарстан Халыклар дуслыгы йорты директоры Ирек Шәрипов «Этномәдәни Казан» туристлык маршруты ачылачагын әйтте. Бу проект кызыклы булачак, халыкка ошар, дип өметләнә ул. Халыклар дуслыгы йорты өчен дә күңелле хәбәр бар: ремонт көтелә.

Утырышта Халыклар дуслыгы йортының Милли бердәмлек көннәре проектын да тәкъдим иттеләр. Фәрит Мөхәммәтшин аны тормышка ашыру өчен ассамблеяның барлык мөмкинлекләрен кулланырга өндәде. Шәһәрдә генә түгел, авылларга чыгып, анда халык белән аралашу, мәдәният, гореф-гадәтләрне өйрәнү файдалы булачагын әйтте. Узган ел чечен, үзбәк һәм кыргыз телләрен өйрәнергә теләүчеләр өчен өстәмә сыйныфлар ачкан күпмилләтле якшәмбе мәктәбенең эшен дә югары бәяләде. Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, туган телне саклау милли-мәдәни автономия җитәкчеләре эшчәнлегендә төп мәсьәләләрнең берсе булырга тиеш. «Заман җиңел түгел, шуңа күрә халык үзен ышанычлы хис итсен, республикада тынычлык булсын өчен, безгә икеләтә тырышырга туры киләчәк», – диде ул.

Сәрия МИФТАХОВА

АЛТМЫШТА ДА КӨРӘШӘБЕЗ

Илдар Мөхәммәтҗанов

17–18 февральдә Казанда герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә газетабыз гамәлгә куйган көрәш турниырының 60 нчысы узачак. Юбилей турнирының яңалыклары да җитәрлек.

Муса Җәлил истәлегенә узучы көрәш турниры алдыннан матбугат вәкилләренең җыелуы матур гадәткә әйләнде. Бу юлы сөйләшүне «Муса Җәлил турниры сезнең өчен нәрсә ул?» соравыннан башладык. Татарстан спорт министрының беренче урынбасары, атказанган спорт остасы Хәлил Шәйхетдинов әлеге бәйгедәге җиңүен искә алды.

– Мин – 1984 елдан бирле көрәшеп йөргән егет. 1991 елда бу турнирда да җиңәргә насыйп булды. Ул минем өчен иң авыр ярышларның берсе булып хәтердә калган. Көрәшчеләрнең саны күп, барысы да бик яхшылап әзерләнгән... Электән шулай булды ул. Егетләрнең бу турнирда катнашып, Муса Җәлил кебек герой буласылары яки тарихка кереп каласылары киләдер, мөгаен, – диде ул.

Турнирның абруен тагын бер кат раслый торган санлы күрсәткечләр белән Татарстан Көрәш федерациясенең башкарма директоры Марсель Таһиров таныштырды. Быелгы ярышларда республиканың шәһәр-районнарыннан, күрше төбәкләрдән барлыгы 400ләп көрәшче, 50ләп команда катнашыр дип көтелә.

– Егетләр инде бик күптән әзерләнә. Бу турнирда күп тапкыр бил алышып, 4 тапкыр җиңү яулаган кеше буларак, шуны әйтәсем килә: монда батыр калу бик авыр. Элек тә шулай иде, хәзер дә. Көрәшчеләр өчен дә, җәмәгатьчелек өчен дә иң дәрәҗәле турнир ул! Көндәшлек һәрвакыт кискен булды. Быел да кимен куймабыз дип өметләнәм, – диде Марсель әфәнде.

Җәлил турнирында 7 мәртәбә җиңү яулаган Ренас Кәлимуллин чарага бәяне яңа буын көрәшчеләр исеменнән бирде.

– Без – көрәшчеләр өчен бик дәрәҗәле ярыш ул. Көрәштәге титулларны санаганда да, иң беренче итеп Җәлил турнирын атыйбыз бит. Шәхсән үзем бу ярышларда быел 10 нчы мәртәбә катнашам. Быел да сынатмаска иде инде, – диде ул.

Тормышта да батыр булыйк!

Батырлык һәм ватанпәрвәрлек тәшенчәләренең мәгънәсе тагын да тирәнәйгән чорда мондый ярышларның әһәмияте бермә-бер арта. Безнең редакция өчен әлеге турнир – спорт бәйрәме генә түгел. «Ватаным Татарстан»ның баш мөхәррире Гөлнара Сабирова әнә шуңа басым ясады.

– Безнең өчен ул – рухи бәйрәм дә. Аның 60 нчысы Казанда узачак. Юбилей турнирына аерым мәгънә өстәргә телибез. Бүген батырлык, ватанпәрвәрлек төшенчәләре тагын да киңрәк мәгънәгә ия. Бу турнирның рәсми ачылышында да чагылачак. Шулай ук быел сәхнәгә турнирда күп тапкыр җиңгән ветеран көрәшчеләребез дә чыгачак. Шул рәвешле батырлары бызның дәрәҗәсен тагын да күтәрәсебез килә, – диде ул.

Газетабызның баш мөхәррире турнирның ни өчен нәкъ менә Муса Җәлил истәлегенә уздырылуын да аңлатты.

– Узган гасырның 20 нче елларында Муса Җәлил «Кызыл Татарстан» («Ватаным Татарстан»ның ул еллардагы атамасы. – **Авт.**) редакциясендә эшләгән. Аның ни дәрәҗәдә батыр һәм ватанпәрвәр шәхес булуын исәпкә алып, бу турнир аның истәлегенә уза башлый. Моннан тыш тагын бер мәгънәсе бар: көрәш ул сөлге тотып көндәшеңне җиңәргә генә түгел, тормышта да батыр булырга өйрәтә. Моны раслаучы мисалларыбыз – көрәштә дә, тормышта да үз урынын тапкан шәхесләребез шактый. Турнирда катнашучы егетләребез дә батыр исемен келәмдә генә түгел, тормышта да акласын иде, – дип сөйләде Гөлнара Сабирова.

Моннан тыш ул турнирны уздыруда зур ярдәм күрсәтүчеләргә, аның төп бизәге булган көрәшчеләргә барыбыз исеменнән рәхмәтен җиткерде:

– Билгеле, 60 ел дәвамында мондый мәртәбәле бәйгене үзебез генә оештырып килә алмас идек. Идея – бер нәрсә, аны бит тормышка ашырырга да кирәк. Бу җәһәттән Татарстанның Көрәш федерациясенә, Спорт министрлыгына без бик рәхмәтле. Һәм, әлбәттә, әлеге турнирны шулкадәр зурлаулары, көрәш тарихында иң мәртәбәле турнир буларак кабул итүләре өчен көрәшчеләребезгә зур рәхмәт!

Быелгы үзгәрешләр

Әйткәнебезчә, быел турнир 60 нчы мәртәбә узачак. Юбилей ярышларының яңалыклары да бар. Беренчедән, быелгы турнирда җиңгән көрәшчеләр Россия беренчелегендә бил алышу мөмкинлегенә ия булачак. Икенчедән, соңгы елларда турнирда батырлар 10 категориядә ачыкланса, быел алар 11 булачак. Авырлыгы 115 килодан артмаган егетләр аерым категориядә бил алышачак.

Батырларга каралган бүләкләргә килгәндә, беренче урынга чыккан батырга – 50 мең, икенче урын өчен – 40 мең, ике өченче урынга 30ар мең сум күләмендә акча бирәчәкләр. Узган елның матур традициясен дәвам итеп, финал ярышында иң яхшы көрәш алымнары күрсәткән егеткә легендар көрәшче, Муса Җәлил турнирында 9 мәртәбә җиңү яулаган Ильяс Галимов исемендәге махсус премия тапшырылачак. Аның күләме – 30 мең сум.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Язучы фикере

Бәлки, кирәге чыгар

Марат
КӘБИРОВ

Чистый ялыктым бу чүп-чардан! Бер урыннан икенчесенә күчереп йөртүдән тәмам туйдым. Бер файдасы тимәгән нәрсәне асрарга кирәкми. Файдасы тимәгән нәрсәнең зыяны тия. Чүплеккә илтәм барысын да!

Мин капканы киереп ачып куям...

Гомер буе диярлек җыелган тимер-томыр бар ишегалдында. Абзар читендә өелеп тора инде ул хәзер, башта капка төбендәрәк иде, аннан өй артына күчте, соңрак мунча артына... Шулай әллә кайларда күченеп йөргәннән соң абзар янына килеп урнашты. Әллә күпме тимер кисәкләре анда. Елдан-елга өстәлеп тә тора, артканнан-арта бара. Иске сарайларны сүткәннән калган капка күгәннәре, келәләр, сынган сәнәкләр, торба өлешләре, тагын әллә нәрсәләр. Кайчагында читтә очраганын да алып кайтканмын инде. Бәлки, кирәге чыгар, дип җыясың шулай. Кайберсенең кирәге дә чыгып куя. Нәрсәнедер кисеп, нәрсәсендер тишеп, ялгап эшкә яратасың да сөенәсең. Әле дә җыеп барганмын әле, сатып ала башласаң, фәлән сум тора бит ул, дисең. Күбесенең кирәге чыкмый. Монда мин бәләкәй чакта колхоз тимерлегеннән күтәреп алып кайткан торба кисәкләренә кадәр бар. Бер урыннан икенчесенә күчереп йөртәсең шулай. Кирәге дә чыкмый, ташларга да жәлке.

Агач өемнәре тора. Бер якта киртәлекләр, икенчесендә баганалар, өченчесендә такталар. Болары да шулай: «Бәлки, кирәге чыгар әле», – дип җыелган. Әллә ничә ел буена торалар инде. Бер урыннан икенчесенә күчеп йөриләр. Күчергән чакта черегән-калтайганракларын кисеп утынга җибәрәсең, калганнары кала. Ул өемнәр дә елдан елга артып тора. Тегене сүтәсең, арурак агачларын алып куясың. Ташларга жәлке. Бәлки, кирәге чыгар әле, дип уйлыйсың. Монысын сүтәсең... агач өеме зураеп кала.

Шуларны бер урыннан икенчесенә күчергәндә бишмәтең кадакка эләгеп ертылып китә дә, өйгә кереп, кием актара башлыйсың. Анда да әйбер тапмалы түгел. Җыелган инде гомер буена. Гел иске-москы. Эшкә кия торганнар. Гадәттә бер генә кием киясең бит инде, калганнары тора шунда. Кирәкми алар. Тик ташлыйсы килми. Тәмам ялкып, чүп капчыгына бәрәм генә дип торганда теге уй кабат баш калкыта да бөтен дөньяңа хуҗа була: «Ташламыйк тор әле. Бәлки, кирәге чыгар...» Ташламыйсың. Ә киемнәр җыела. Бишмәтеңне ертып кергәч, теге капчыкларны актарасың, тартмаларны айкап чыгасың. Бөтен нәрсә бар. Тик сиңа кирәкле бишмәт кенә табылмый. Шулхәтле ыбыр-чыбыр арасыннан тиешлесен табып буламыни!

Бер мин генә шулайдыр инде, дип уйлыйм башта. Алай түгел икән. Күпме дус-ишкә керсәм дә, хуҗалыкның берәр почмагында шундыйрак өемнәр тора: тимер-томыр, кирпеч, агач... Алар да минем шикелле бер урыннан икенчесенә күчереп йөртәләр икән. Бәлки, кирәге чыгар, дип җыялар. Авыл кешесе шулай кызык инде ул. Кирәк чагында барып кына алырга кибете дә якын түгел бит. Я район үзәгенә, я шәһәргә чабарга кирәк. Шулай булгач, теләсәң-теләмәсәң дә, саклабрак торырга мәҗбүр буласың. Бәлки, кирәге чыгар, дисең. Авыл кешесе сакчыллык мәсьәләсендә аеруча вакчыл ул. Һәр чорның авырлыгын фәкать үз көче, үз чыдамлыгы белән җиңеп чыгарга өйрәнгән бит инде. Заманында ыштан бөрмәсенә кыстырып алып кайткан җиде-сигез бөртек бодай өчен дә еллар буена төрмәдә утыручылар булган. Шуңа күрә һәрбер нәрсәне кадерләп тота хәзер. Бу аның канына сеңгән. Бер нәрсәне дә тик торганнан гына чүплеккә илтеп ташламый. Һәр әйбергә, һәр күренешкә хөрмәт белән карый, бәлки, кирәге чыгар, дип уйлый.

Исәпләп карасаң, бу иске-москылар әйбер генә түгел бит әле, алар беркадәр тарих та. Менә бу баганаларны җиденче сыйныфта укыганда иптәш малай белән төнлә урманга барып аркылы пычкы белән кисеп алып кайткан идек. Күтәреп салырга көч җитмәгәч, арба читенә киртәләр сөяп тәгәрәтеп мендердек. Бу такталарны әни юнәткән иде, һәркайсына аның кулы тигән. Кадакны кибеттән алырга мөмкинлек булмагач, бишле тимерчыбыктан Шәфыйк бабай ясап биргән иде. Һи-ии-и... Уйлап утыра башласаң, болар иске-москы өеме түгел, ә гаиләнең тарих китабы шикелле. Никадәр истәлекләр саклана бу өемнәрдә, бары тик җыеп алып, адәм теленә күчерергә генә кирәк. Һәр әйбергә карап бер китап язарлык...

Шулай дип уйлыйм да күңел нечкәреп китә. Һәм мин шар ачылган капканы ябам да чүп-чар түгәргә дип йөк машинасы белән килгән иптәш егеткә кул селтим.

– Ярый, түкми торыйк... – Һәм аның сораулы карашына җавап итеп, өстәп куям: – бәлки, кирәге чыгар әле...

ҖИР ТЕТРӘГӘНДӘ БИЛ АЛЫШУ

Төркиядә 6 февраль таңында башланган фаҗига мәйданыннан Голливудның Кыямәт сценарийларын сурәтләгән фантастик кинолар сюжетын хәтерләткән видеохәбәрләр килеп тора. Трагедиянең масштабын әле һаман да тулысынча билгеләп булмый, чөнки җимерекләр чистартылып бетмәде. Йорт хәрабәләре астыннан исән кешеләрнең тавышлары ишетелә дигән хәбәрләр дә күренә.

Минуслы температурада, ташлар астында калып, җиде-сигез тәүлек яткан кешеләрнең исән килеш коткарылуы, чынлап та, таң калырлык хәл. Бу юллар язылганда, инде 41 мең кешенең һәлак булуы рәсми рәвештә игълан ителде. Чып-чын могҗизага тиң сюжетларга да тап буласың. Сишәмбе көнне Кахраманмараштан гаҗәп хәбәр алынды. Бер хатын экскаваторны туктата да җимерекләр астында калган балаларын коткаруны үтенә. Коткаручылар, аны тыңлап, балаларны казып чыгаралар. Әмма әниләренә бирергә дип, хатынны эзли башлагач, таба алмыйлар. Юкка чыккан. Балаларның өлкәне – 13 яшьлек малай исә үз әниләренең дүрт ел элек үлгән әйтә.

Төрек трагедиясе үзенең масштабы белән гасырның иң зур алты катастрофасы исемлегенә кертелде. Бу юлларның авторы егерменче гасырдагы иң зур җир тетрәүләр исемлеген карады. Йөз елга иң зур масштаблы 6 җир тетрәү теркәлгән. Соңгысы – совет кешеләренең хәтеренә уелып калган Спитак фаҗигасе 6,8 баллы булган, 25 мең кешенең гомерен өзгән, 140 мең кеше гарипләнгән.

Яңа гасырның 23 елы гына үтүгә карамастан, зур югалтуларга китергән 6 җир тетрәү теркәлгән инде. Катастрофаларның ешлыгы арта, масштабы үсә, корбаннар саны ишәя. Галимнәр алдагы елларда җир тетрәүләр саны артачагын, куәте үсәчәген фаразлый. Җир тетрәүләр саны һәм масштабы планета әйләнешен акрынайтканда үсә, диләр. 2014 елдан башлап Җир акрыная, бу – факт. Дөрес, тәүлектәге үзгәрешләр берничә миллисекунд кына тәшкил итә, әмма балансның шундый кечкенә тайпылышы да зур фаҗигаләргә китерә ала. Болай планета үзе бер акрынаеп, бер тизләнеп тора.

Юк, бу язмада Җир шары масштабындагы табигый катастрофаларның артуы хакында сөйләшмибез әле. Төрек фаҗигасенең без яшәгән җәмгыятьләрдә биргән кайтавазы күбрәк кызыксындыра. Соңгы елларда үзен куәтле держава буларак тәкъдим иткән һәм еш кына Америкага каршы чыгучы дәүләт позициясенә баскан Әрдоган Төркиясенең эчке каршылыклары турында сөйләшербез.

Мондый масштаблы фаҗигаләрнең бер уңай ягы бар: ул кыска гына вакытка булса да дәүләтләрне берләштерә. Кичә генә бугазлашу хәлендә килгән дошманнар да, коралларын ташлап, бердәм рәвештә кулга-кул тотыналар. Үч алу тойгысын кешелеклелек, мәрхәмәтлелек хисләре алыштыра. Бу юлы да шулай булды. Илләр ярдәмгә ашыктылар, игелек үрнәкләре турында хәбәрләр таралды. Коткаручылар үзләре тапкан миллионлаган һәм йөз меңләгән акчаларны ияләренә кайтарып бирделәр. Ятимнәрне үз канаты астына алырга теләүчеләр ишәйде. Рәсми төрек хакимиятләре туганнарын югалткан гаиләләргә күләмле финанс ярдәме, йортсыз-җирсез калучыларга бер елга фатир өчен түләп тору һәм ун мең лира акчалата булышлык вәгъдә итә, ел эчендә яңа фатир төзеп өлгертергә ышандыралар. Катардан зур күләмдә финанс ярдәме килергә тора, башка дәүләтләр дә үз кулларын сузалар. Кичә генә ярым сугыш хәлендә булган греклар, мәсәлән, беренчеләрдән булып ярдәмгә килде. Грекларның тагын бер нәрсәсе ошады миңа. Француз карикатура журналы «Шарли Эбдо» бу юлы да үзенең пычрак йөзен күрсәтте: корбаннардан көлеп карикатуралар урнаштырды. Греклар шуңа җавап итеп «Без барыбыз да – төрекләр» дигән лозунг белән чыкты.

Шәфкатьлелек үрнәкләре белән беррәттән түбән гамәлләр белән танылучылар да мәйданга чыкты. Мародерлар ишәйде. Эш шуңа барып җитте: кайбер илләр үз коткаручыларын, иминлек гарантияләнмәү сәбәпле, кире чакыртып алды. Минем телефонга мародерларга беренче кисәтүдән соң атарга дигән указ күчермәсе дә килде, дөреслеген тикшереп өлгермәдем әле.

Әрдоган җитәкләгән ил соңгы еллар кризисын авыр кичерә. Бердән, технологик товарларның җитештерелүе һәм экспорты арта, икенче яктан, илдә – бик зур инфляция, лира курсының масштаблы мәтәлчек атып, түбәнгә тәгәрәве. Халыкта зур ризасызлык уята торган нәрсәләр, билгеле. 6 февраль тетрәве бик катлаулы вакытка туры килде. 14 майда илдә – Президент сайлавы. Ул июньдә буласы иде, Әрдоган бер ай алга күчерде. Җир тетрәү исә лидерның рейтингына суга торган бик ямьсез фактларны ачты. Йортлар бик тиз җимерелеп төште. Төзелеш кагыйдәләре бозылганлыгы ачыкланды. Хәтта җир тетрәү туктаганнан соң да колачын җәеп җиргә яткан яисә ишелеп төшкән күпкатлы өйләр булды, диделәр. Капитализмның төп сыйфаты – ачкүзлелек, үзкыйммәтне киметү максатыннан куркынычсызлык техникасы кагыйдәләрен тупас бозу фактлары күпләп өскә калкып чыкты. Югыйсә Төркиядә җир тетрәүләр еш була. Сейсмик яктан тотрыклы өйләр төзү кирәклеге сүзсез дә аңлашыла. Аннан соң Әрдоган төзелешкә рөхсәт бирүне җиңеләйткән. Бернинди махсус белеме булмаган кешеләр төзелеш компанияләрен җитәкләгән. Хәзер алар дистәләп-дистәләп кулга алына. Лидерның абруен нык төшерә торган нәрсәләр, әлбәттә. Дөрес булса, рейтинг 19 процентка гына калды, диләр.

Әмма бит вазгыять шундый: сәяси көрәш вакыты түгел, бәлагә каршы кулга-кул тотыну сәгате. Вәләкин Төркиядә хәл шундый: ил күп елларда бирле чатнап икегә бүленгән. Мөселман катлавы белән материализм тарафдарлары килешмәс көрәш алып баралар. Бу гасыр башында көчләр чагыштырмасы чак кына мөселманнар тарафына авышты. Әрдоганның озакка сузылган идарәсе – шуның нәтиҗәсе. Ә озак җитәкчелек иткәндә, хаталар ясалмый калмый. Бигрәк тә аяк чалучыларның зур армиясе белән тартышырга туры килгәндә.

Беренче йортлар авып та өлгермәде, төрек оппозициясенең атеистик катлавы кычкырып аваз бирде. Бәхетсезлекнең мөселманнарны сайлаган өчен җәза икәнлеген кычкыручы сәясәтчеләр табылды. Хәтта коткаручыларның җимерекләр астыннан исән кешеләрне тартып чыгарганда: «Аллаһу әкбәр!» – дип кычкыруларын гаепләүгә барып җиттеләр. Аннан соң төп уен картасын өстәлгә чыгарып салдылар. Корбаннар саны зур булуга хакимият гаепле. Әрзин шәһәре мэры, оппозицион Әлмәсоглу фигурасы байрак итеп күтәрелде, чөнки 42 мең кешелек шәһәрдә бер йорт та җимерелмәгән, бер кеше дә үлмәгән. Легенда тудырылды: Әлмәсоглу куркыныч урыннарда йорт төзү өчен бер рөхсәт тә бирмәгән, басымга каршы торган, сатылмаган. Әлмәсоглуның хакимияткә 2019 елда гына килүе, җир тетрәүгә бирешмәгән йортларның күбесе ул килгәнче төзелгән булуын әйтеп тормадылар.

Йортлар төзү өлкәсендә ике әһәмиятле факт бар ләкин. Беренчесе, төрек дәүләт төзелеш компаниясе – Төркиянең төзелеш идарәсе (ТОКİ) төзегән 133 мең 759 бинаның берсе дә җимерелмәгән, хәтта тәрәзәләре дә ватылмаган. Авып төшкән өйләр яңашәсендә мәгърур торалар. Бу фактны рәсми матбугат югары күтәрә, оппозиционерларның дәлилләре шулай кире кагыла. Хәзер ТОКİ бәлагә тарыганнар өчен 30 мең йорт төзергә әзерләнә. Икенчесе шул: җимерелгән йортларның 98 проценты 1999 елга кадәр, ягъни Әрдоган хакимлеккә килгәнче төзелгән. Төрек лидерын берникадәр аклый инде бу фактлар. Әмма май сайлавы нинди нәтиҗәләр күрсәтер – әйтү кыен. Оппозициянең сөякләр өстендә биюен, канда пиар ясарга тырышуын ил халкы ничек бәяләр?

Мөнәсәбәтләр ачыклый торган чак түгел бит. Үзара дошманлыкны онытып, ярдәмләшә торган вакыт. Сүз бит шахмат тактасында фигуралар алышыну турында гына бармый, гади рокировка гына түгел, төбәк державасыннан дөньякүләм лидерлыкка омтылучы дәүләтнең мәсләге, идеологиясе үзгәрү күзәтелергә мөмкин. Бу үз чиратында Кара диңгез һәм Урта диңгез буенда көчләр чагыштырмасы үзгәрүгә дә китерә ала. Әйтик, хакимлеккә оппозиция килеп, ул Америка һәм Европа ягына таба авышса (җиңсәләр, шулай булыр да ул), Россия – Төркия мөнәсәбәтләре чатнарга мөмкин. Бу үз чиратында Россиянең көнбатышындагы конфликтка тәэсир ясый ала. Нәрсә генә булмасын, май уртасыннан соң Каф тавы артында зур социаль тетрәнүләр килеп чыгу ихтималы зур. Сәяси көчләрнең зур фаҗига фонында да бил алышулары көрәшнең кискен һәм килешмәүчән булачагына ишарә итә.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

САНАЛ(МА)ДЫК - 2

Декабрьнең соңгы көннәрендә игълан ителгән җанисәп нәтиҗәләре әле һаман күңелне тырнап тора. Шулай булмый ни! Халык санын алу нәтиҗәләре билгеле булгач та туган сораулар әле бүген дә һавада эленеп кала бирә бит. Ни өчен илдә татарлар 600 меңгә (!) кимегән дә аларны кайдан эзләргә? Ун елдан тагын шул ук тырмага басмас өчен бүген нәрсә эшләргә? Ни өчен кайбер төбәкләрдә татарлар коточкыч дәрәҗәдә кимегән? «ВТ» хәбәрчесе читтә яшәүче милләттәшләребез белән элемтәгә кереп, шул сорауларга җавап табарга тырышты.

Таңсылу Галимова

Битарафлык «бүләге»

Россиядәге татарларның ярты миллионнан артыгракка кимүен ишеткәннән бирле бу коточкыч күрсәткечкә китергән сәбәпләрне барлыйбыз. Белгечләрнең бер ише моны җанисәпнең иң уңайсыз чорда – илдә коронавирус котырган вакытта уздырылуына бәйләп аңлата. Халык санын алуны оештыруга канәгатьсезлек белдерүчеләр дә шактый. Ничек кенә булмасын, саннар теркәлгән инде һәм аларның чынбарлыкка туры килмәве көн кебек ачык.

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров җанисәп нәтиҗәләре игълан ителгән беренче көннән үк милләттәшләребезгә бәйле саннарның дөреслеккә туры килмәвен искәртте. Конгрессның экспертлар комиссиясе бүген Россиядә яшәүче татарлар 5 миллион 500 меңнән дә ким түгел дип санап чыгарган. Хәер, татарлар яшәгән төбәк вәкилләре үзләре дә кәгазьдәге саннарның чынбарлыкка якын да килмәвен искәртә.

Җанисәп нәтиҗәләре буенча Мәскәүдә, Чиләбе, Свердловск, Ульян, Оренбург өлкәләрендә татар халкының аеруча нык кимүе күзәтелә. Әйтик, шул ук Свердловск өлкәсендә татарлар 50287 (!) кешегә азайган. Татарстанның Уралдагы даими вәкиле урынбасары Фәвия Сафиуллина бу саннар дөреслеккә туры килми дип саный.

– Кәгазьдә күрсәтелгән 50 мең татарның чынлыкта 15 меңе кимегәнгә ышана алам әле. Ник дигәндә, соңгы арада күзәтелгән миграция, ассимиляция, урбанизация процесслары төбәктәге халык санына да йогынты ясый. Җанисәп узган саен, Аллаһка шөкер, Свердловск өлкәсендә татарлар – икенче урында, дип сөенә идек. Соңгысының нәтиҗәләре буенча өченче урынга төштек. Милләтен күрсәтергә теләмәүчеләр икенче урынга менде. Исәпкә алынмаган ким дигәндә 35 мең татар шулар арасында булырга тиеш, – ди ул. – Күп кешенең өенә сан алучы килмәгән. Кемдер җанисәпкә Дәүләт хезмәтләре порталы аша катнашкан, кемдер бу хакта бөтенләй белмәгән.... Ничек кенә булмасын, мондый эшне көннән-көн битарафлана барган халык иркенә калдыру дөрес нәрсә булмады. Җанисәпкә дәүләт тә, халык үзе дә җавапсыз карады.

Киләсе җанисәптә тагын да мөшкелрәк хәлгә калмас өчен, иң беренче чиратта, әнә шушы битарафлыктан котылырга кирәк дип саный милләттәшебез.

> Бер бармак тиз сына, барыбыз бергә йодрыкланып, атлый башлар чак. Милли үзаңны арттыру эшендә безгә динебез дә ярдәмгә килә ала. Без бит Ходай Тәгаләдән генә куркабыз. Дин әһелләребез тарафыннан татарлар белән милләт кадере, милли үзаң, тамырларыңны белү турында сөйләшүләр, шул юнәлештә эш алып барылса, нәтиҗәсе, һичшиксез, булачак.

Бер кавем

Бөтендөнья татар конгрессының Башкортстандагы вәкиле Альфред Дәүләтшин да – шул фикердә. Соңгы җанисәп нәтиҗәләре буенча Башкортстан татарлар иң күп кимегән төбәкләр унлыгында – алтынчы урында. Ун ел эчендә биредә яшәүче милләттәшләребез 34,7 мең кешегә кимегән. Ләкин Альфред Дәүләтшин бу саннардан бигрәк, халыкның кимү процентына игътибар итәргә куша.

– Ун ел эчендә Башкортстанда татарлар 3 процентка гына кимегән. Татарларны 30–40 процентка азайган башка төбәкләр белән чагыштырганда бу – бик аз сан. Дөрес, сыйфатлы татарның кимүе сизелә. Алар, нигездә, Казан, Мәскәү, Санкт-Петербург кебек зур шәһәрләргә, чит илләргә китә, – ди ул. – Безгә – татарларга бер-беребезне тыңларга, ишетергә кирәк. Бер-беребезгә гаеп атып утырудан туктыйк. Төбәкләр арасында чикләр куймыйча, бигрәк тә Идел – Урал төбәкләре белән элемтәләрне ныгытырга кирәк. Бүген чит төбәкләрдә яшәгән татарларга игътибар җитеп бетми. Без барыбыз да – бер кавем. Самара, Уфа, Ульянда яшиме ул, барыбыз да – шул бер татар. Бер-беребезне бер татар иле итеп күрсәк, уртак сүз белән, проблемаларны уртага салып сөйләшсәк, соңгы җанисәптәге хаталар киләчәктә кабатланмас иде.

Түбән өлкәсе татарлары конгрессының башкарма комитет рәисе Ринат Насыйров җанисәпне уздыру тәртибеннән дә, аның нәтиҗәләреннән дә канәгать түгел.

– Җанисәп «узганмы – узган» рухында башкарылган эш кебек булды. Элек халык санын алу күбрәк калаларда җитешсезлекләр белән узган булса, быел ул авылларда да бик түбән дәрәҗәдә үтте. Без үзебез дә 2010 елдан бирле күп ялгыш адымнар ясадык. Шул ук ипотека программасы аркасында авылларда яшәүче бик күп татар шәһәргә күченде. Шул рәвешле алар 90 процент руслар яшәгән җирлеккә килеп урнашты. Аларны үзебездә тотып калу өчен, мәдәният, мәгариф буенча да эшләрне эшләп өлгермәдек. Бүген аларны эшли башларга кирәк. Башкача булмый, – ди ул.

Дөрес, Ринат әфәнде төбәктә милләттәшләребез саны кимүгә китергән берничә күренеш барлыгын да яшерми.

– Без зур шәһәрләр янында урнашкан татар авылларының акрынлап калага кушылып китүен дә сизми калдык. 1 мең кеше яшәгән, 90 процентын татарлар тәшкил иткән авылда 25 катлы 4–5 йорт пәйда булды. Шул рәвешле 90 процент татардан 10 процентка гына калдык. Аның өчен монда башка милләт вәкилләре килеп тулды. Мәктәп тә, балалар бакчалары да башка дәрәҗәгә күчте. Безнең Кырымкүл авылында 1450 бала укый торган өр-яңа мәктәп төзелде. Шунда нибары 450 татар баласы гына укый, – ди ул.

Бәйрәм генә җитми

Ульян өлкәсе милләттәшләребез сафы иң нык сирәгәйгән төбәкләрнең беренче дүртлеген йомгаклый. Биредә татарлар 38,5 мең кешегә кимегән. Өлкәнең татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Рәмис Сафин исә бу саннарга гаҗәпләнми.

– Бу саннардан трагедия ясамас идем. Җанисәпне оештыруда кытыршылыклар күп булды. Аның онлайн рәвештә узуы да йогынты ясады. Өлкән буын вәкилләре тиешенчә катнаша алмады. Моңа Ульян өлкәсендә катнаш никахларның күплеге дә этәргеч булды. Аларның балалары татар булып язылмый бит инде. Катнаш никахтан урыслар туа, – ди ул.

Удмуртия татарларының милли-мәдәни автономиясе рәисе Рәмзия Габбасова да катнаш никахларны безгә иң төп аяк чалучыларның берсе дип атый.

– Хәзер бит һәр ике гаиләнең берсе катнаш. Җанисәпнең уздырылу рәвешеннән дә канәгать түгел без. Яңа заманча ысулны кертәбез дип, онлайн тавыш бирүне керттеләр. Ул халыкта сүлпәнлек тудырды. Мәктәпләребездә татар теле укытуның кимүе дә йогынты ясады. Бездә, әйтик, 1990 еллардагы күтәрелеш чорында 1200 бала татар телен фән буларак өйрәнсә, бүген 520 бала гына фән буларак татар телен өйрәнә. Татарлыкны гаиләдә саклау гына җитми. Безнең татар балалар бакчалары, татар мәктәпләре, югары уку йортлары булырга тиеш. Шундый чылбыр булганда гына татарлыгыбыз тулы канлы булачак. Милли бәйрәмнәр, телне саклауга юнәлдерелгән башка чаралар шушы чылбырны саклауның ярдәмчеләре генә, – ди милләттәшебез.

Җанисәп нәтиҗәләренә ышансаң, Удмуртиядәге татарлар 30,8 меңгә кимегән. Рәмзия Габбасова сүзләренә караганда, ике җанисәп арасында саннар элегрәк тә кими барган анысы. Шуңа Удмуртиядә ун ел эчендә ун мең чамасы татар кимегәндер дип фаразлаган булган алар. Әмма ахыргы саннарның көткәннән өч тапкыр күбрәк булачагын күз алдына да китермәгәннәр. «Милли үзаң дәрәҗәсе бик югары булган Удмуртия татарлары өчен бик зур сан бу», – дип саный Рәмзия ханым.

Үзгәрешсез булмый

Бөтендөнья татар конгрессының Пермь краендагы вәкиле Сәлим Назин да халык санын алганда утыз ел дәвамында күзәтелгән тенденция соңгы җанисәптә кисәк кенә үзгәрә алмый дип саный. Бу урында конкрет саннар да китерде ул. Әйтик, 1989 елны Пермьдә – 150460 татар, 2002 елда – 138500, 2010 елда 115544 татар исәпләнгән. Соңгы җанисәп нәтиҗәләре буенча биредә 92472 милләттәшебез көн күрә.

– Халык санының кимеячәге билгеле иде. Ничек кенә тырышсак та, демографик хәл яхшырмый бит. Шулай да төбәктәге татарлар саны 20 меңгә үк кимер дип көтмәгән идек. Бездә милли үзаң үзгәрүчән. Бу сәясәт, икътисадка бәйле. Авыл яшьләре шәһәргә китә. Ә анда – рус мохите. Кеше үзенең тамырларына әһәмият бирми башлый, телне югалта. Аннары илебез соңгы елларда чит телләргә күбрәк әһәмият бирде. Урамдагы реклама такталарын карагыз. Андагы сүзләрнең күпмесе инглиз, күпмесе рус, күпмесе татар телендә язылган? Шул рәвешле без үз кулларыбыз белән үзебез үк милли мохитне югалтабыз, – ди Сәлим әфәнде.

Киләсе җанисәпкә кадәр татарлыкны саклап, сан ягыннан артыйк дисәк, тормышыбызга берничә үзгәреш кертергә кирәк, дип саный ул. «Ир кеше үз функциясен үтәсен, гаиләсен тәэмин итә алсын өчен, күбрәк акча эшләргә тиеш. Шуңа күрә илдә ир-атларның хезмәт хакын арттыру ягын кайгыртырга кирәк. Хатын-кызның бала ялында булган елларын аның эш стажына кертү дә мөһим. Мөселман хатын-кызлары өчен абортны тыю да нәтиҗә бирер иде. Мөселманның төп вазыйфасы кавемен арттыру бит. Милли үзаңны үстерү юнәлешендә дә даими эш алып барырга кирәк», – дип саный Сәлим Назин.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ТАТАРЛАР ИҢ КҮП КИМЕГӘН ТӨБӘКЛӘР

Төбәк	2021	2010	Күпмегә кимегән: Саннарда	Күпмегә кимегән: Процентларда
Мәскәү	84 373	149 043	– 64 670	– 43,4
Чиләбе өлкәсе	120 242	180 913	– 60 671	– 33,5
Свердловск өлкәсе	93 516	143 803	– 50 287	– 35
Ульян өлкәсе	111 365	149 873	– 38 508	– 25,7
Оренбург өлкәсе	116 605	151 492	– 34 887	– 23
Башкортстан Республикасы	974 533	1 009 295	– 34 762	– 3,4
Самара өлкәсе	94 452	126 124	– 31 672	– 25,1
Удмуртия Республикасы	67 964	98 831	– 30 867	– 31,2
ХМАО	79 727	108 899	– 29 172	– 26,8
Пермь крае	92 472	115 544	– 23 072	– 20

Зөһрә САДЫЙКОВА

ЭШЛӘГӘЧ, АШЫЙСЫ КИЛӘ

Газетабызның узган саннарында республика районнарында халыктан җыела торган сөт бәяләренә күзәтү ясаган идек. Язма басылып чыккан көнне үк Апас районының Олы Бакырчы авылыннан борчулы мөрәҗәгать килеп иреште. «Башка түзәр чамабыз калмады. Гыйнварда халыктан җыела торган сөткә түләү бер сумга төшкән иде. Инде 1 февральдән тагын бер сумга киметеп, сөтнең литрына 24 сум түләмәкче булалар. Болай булмый бит инде. Мал асрауның кызыгы калмады», – дип шалтыратты Миләүшә Булатова. «Килеп күрегез әле безнең авылны», – дип тә чакыргач, юлга кузгалдык.

Альберт Каюмов

Аңлатучы юк

Апас районының Олы Бакырчы авылы матур, төзек, мул тормышлы. Җирлеккә ике авыл керә. 328 хуҗалыкта 580 кеше яши. 197 хуҗалык – Бакырчы авылында. Күптән түгел генә авыл үзәгендә почта, авыл советы, клуб, музейны берләштергән ялт итеп торган матур бинаны сафка бастырганнар. Аннан ерак түгел генә азан тавышы ишетелеп торган мәчетләре дә бар. Иң мөһиме, анысы буш тормый. Без барган көнне дә утызлап ир-ат җомга намазыннан чыкты.

– Мәчетебезнең буш торганы юк. Шөкер, халык динле бездә. Намазга йөриләр, Коръән ашлары уздыралар. Мәчеткә ярдәм итүче эшмәкәр егетләребез дә бар, – ди авыл хәзрәте Шәүкәт Гайнетдинов.

Мәчеттән ерак түгел генә авылның мәктәбе, балалар бакчасы, Шәүкәт Галиев исемендәге музейлары бар. Кызганыч, башка бик күп авылларга хас булганча, балалар саны гына аз. Зур мәктәпләрендә 22 укучы белем алса, бакчага 7 бала йөри.

– Авылыбыз бик матур. Рәхәтләнеп яшәр өчен барлык мөмкинлекләр бар. Тик, аяныч, кеше генә юк. Яшьләр шәһәргә китә, авылда өлкәннәр генә утырып кала. Берни дә эшләр хәл юк, – ди авыл җирлеге башлыгы Фәрит Вәлиев.

«Апас мол» агрофирмасында 47 кеше эшли. Авылның балта осталары да, умартачылары да бар. Шулай да җирле халыкның күпчелеге терлекчелек белән шөгыльләнә. 43 хуҗалыкта 250 баш мөгезле эре терлек асрыйлар. Аларның йөздән артыгы – сыерлар. Алтышар-җидешәр баш сөтлебикә тотучылар да бар. Кайбер хуҗалыкларда мөгезле эре терлекләр саны 30га кадәр җиткән. Тик күпләп мал тотсалар да, авылда бер генә фермер да юк.

– Барлык өстенлекләрен аңлатып торсак та, бездә халык фермер хуҗалыгы булып теркәлүгә башы-аягы белән каршы. Үзләре тырыш, эш сөючән, тик программаларга керергә, дәүләттән акча алырга теләмиләр. Белмим, куркумы бу, дәүләткә бәйлелек, дип кабул итүме, бары тик үз көчләренә генә ышанумы? Әйтә алмыйм, – ди Фәрит Вәлиев.

Редакциягә шалтыраткан Миләүшә һәм Наил Булатовлар да төп керемнәрен терлек асрап алалар. Бүген аларның хуҗалыгында сигез сыер бар.

– Гомер буе терлек тоттык, – диде хуҗабикә. – Без аларны аз булса да кереме булыр, дип тотабыз. Соңгы 3 елда 6–8 баш сыер савабыз. Сөт сатып, кулга ай саен акчасы кергәч, тормыш итәргә иркен дә, рәхәт тә бит.

Тик халыкның кәефен сөт бәяләренең әледән-әле уйнап торуы гына кыра. Миләүшә апа әйтүенчә, июньдә сөт өчен 27 сумнан түләгәннәр. Июль башында – 25 сум 50 тиен булган да, 16 июльдән 22 сумга төшкән. 1 сентябрьдән 15 гыйнварга кадәр исә 26 сумнан түләгәннәр.

– Сөтнең литрына 26 сумнан түләгәндә бик канәгать идек, зарланмадык. Алты сыерның сөтен сатып, аена 70әр мең сум акча алып килдек. 80 меңгә якын алган вакытлар да булды. Без бер елда 900 мең сумлык сөт сатабыз. Аз акча түгел бит. Тик гыйнвар уртасыннан сөт хакы 25 сумга төште. Әле менә сөт җыючыбыз, 1 февральдән 24 сумга калачак, дип хәбәр итте. Шуннан соң сезгә мөрәҗәгать иттек.

Кереме шактый булса да, мал тотучының чыгымы да, мәшәкате дә күп шул.

– Йокыдан иртәнге 4 нче яртыда торабыз, – ди Миләүшә апа. – Чәйләр эчеп, сарайга чыгабыз. Терлекләрне ашатып, асларын чистартып, савып, сөтләрне тапшырып, 7 нче яртыда өйгә керәбез. Шуннан соң машинага утырып, кибетебезгә кузгалабыз. Төш җиткәндә кайтып, тагын сарайга чыгабыз. Шулкадәр хезмәт куйгач, нәтиҗәсен дә күрәсе килә. Ризыгын да бушка китереп бирүче юк. Барысын да сатып алабыз. Узган ел 124 төргәк печән белән салам (колхоз бер төргәген 250 сумнан гына бирде), алты «КамАЗ» җом, 40 капчык көрпә, 5 тонна ашлык алдык. Сөт бәясе 26 сум булганда иген, печән, җом алган чыгымны 1,5 ай сөт сатып капладык. Ул вакытта алты гына сыер савыла иде әле. Тик хәзер сөт 24 сумга төшеп утырса, шулкадәр көч кертеп асрауның бер кызыгы да калмый бит.

Хатынының фикерен гаилә башлыгы да куәтләде.

– 24 сумга кала дип әйткәч, әлбәттә, кәеф төште. Мал тотуның бер файдасы калмый бит. Нәрсә телиләр, шуны эшлиләр. Безгә сөт бәясе төшүнең сәбәпләрен булса да яхшылап аңлатсыннар иде. Беркемгә берни аңлатучы юк, – дип сүзгә кушылды Наил Булатов. – Без сөт җыючы Дамирдан да канәгать. Вакытында килә, китә, акчаны соңга калмыйча бирә. Сөтнең сыйфатын да карап, тикшереп торалар. Безгә дәгъва белдергәннәре юк.

Сөт бәясенең түбән булуы Булатовларны гына түгел, башкаларны да борчый. Тик күпчелеге тел яшереп калуны өстенрәк күрә.

– Безгә хак төшерү сәбәпләрен аңлатучы юк. Килеп әйтәләр дә, без риза булып торабыз. Җәйгә бәяләр тагын төшәчәк инде, – диде исемен газетада күрсәтмәүне сораган бер апа. – Ирем авырый, эшләми. Шул сөт акчасына яшибез. Узган айда 4 сыер савып, аена 34 мең сум акча алдым. Мал тотуның чыгымы да күп, әлбәттә. Тик ай саен акчасы кереп баргач, ваклашмыйбыз. Дүрт сыерның дүрт бозавы да була бит әле. Берсен үзебезгә суйсак, калганын иткә сатабыз. Аның кереме каралты-кураны караргa китә.

«Үзгәрмәячәк»

Билгеле, халыкның зарын авыл советында да беләләр.

– Ул сөт проблемасы ничә елдан бирле дәвам итә инде, – дип күрсәнде Фәрит Вәлиев. – Яңа сөт комбинаты ачылгач, бәясе күтәрелер дип көткән идек, тик әлегә өметләр акланмады. Үзем колхоз рәисе булып эшләгәндә, сөтнең литрын 12 сумнан тапшыра идек. Ул вакытта «Волжанка» суы 17–18 сум тора иде. Судан да арзанрак иде сөт. Бүген дә шул ук хәл күзәтелә. Февральдә тагын бер сумга төшерәм, дип язган иде сөт җыючы. Анысы булырмы, юкмы, әлегә төгәл билгеле түгел. Әлегә сөт комбинаты бәяне шул ук дәрәҗәдә калдырган.

Җирлек башлыгы әйтүенчә, сөт бәяләренең арзан булуында халыкның да гаебе бар. Аның фикеренчә, хуҗалыклардан җыелган сөтнең сыйфаты торыклы түгел.

– Сөт җыючылар сөткә су кушудан, антибиотиклы булудан зарлана, – ди ул. – Барысы да алай эшләмидер, ләкин бер кашык деготь бөтенесен бозып куярга сәләтле.

Әлеге мәсьәлә буенча Апас районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Радик Гыйсмәтов белән дә сөйләштек. Ул безгә: «Әлегә сөт бәясен бер дәрәҗәдә тотабыз, үзгәрешләр булмаячак», – дип вәгъдә бирде.

– Әлеге вакытта бездә сөт өчен халыкка 25 сум түлиләр. Чыннан да, 24 сумга төшерү турында сүз булган иде, тик без моны туктатып тордык. Район башлыгы белән бергә барлык сөт җыючыларны җыеп әйтергә уйлыйбыз, – диде ул.

Сөт бәясе түбән булу сәбәпләренә килгәндә, идарә башлыгы беренче чиратта халыктан җыела торган сөтнең сыйфаты начар булуга ишарәләде. Аның сүзләренчә, халык сөткә су кушу белән мавыга, антибиотиклар да еш чыга. Икенче сәбәп – сөтнең арадашчылар кулыннан узуы.

– Бүген Апаста халыктан сөтне 16 кеше җыя. Сөт җыючылардан заводка барып җиткәнче, берничә кул аша уза. Бәяне шул да түбәнәйтә, – дип аңлатты Радик Гыйсмәтов. – Әйтик, Күккүз җирлегендә яшәүче Алсу апа сөтне үзе эшкәртә. Халыктан сөт җыя да, каймагын, эремчеген ясап, Казанга базарга алып барып сата. Ул аена 27 сум бирә. Киләчәктә районда кооператив ачарга планлаштырабыз. Шуннан соң дүрт машина алып, заводка сөтне турыдан-туры китерә торган булсак, бәлки халыкка да күбрәк түли алыр идек.

ХАЛЫКТАН ҖЫЕЛА ТОРГАН СӨТ БӘЯЛӘРЕНЕҢ ТҮБӘН БУЛУ СӘБӘПЛӘРЕ

1. *Районның сөт тапшыру пунктларыннан еракта урнашуы.*
2. *Сөтнең кулдан-кулга күчеп йөрүе. Халык – сөт җыючы – трейдер – сөт комбинаты. Баскыч биегрәк булган саен, авыл кешесе кулына килеп ирешә торган акча кимрәк була.*
3. *Сөтне аз күләмдә тапшыру. Ягъни районда терлек саны азрак булган саен, сөт бәясе шуның кадәр кимрәк була. Чөнки чыгымнар үз-үзен акламый.*
4. *Сөткә ихтыяҗ киму. Кешенең сатып алу мөмкинлеге киму сәбәпле, сөт эшкәртү дә азая.*
5. *Халыктан җыела торган сөтнең сыйфаты торыклы булмау.*
6. *Трейдерлар арасында килешү. Өстәмә табыш алыр өчен, бер-берсе белән килешеп, бәяләрне бер дәрәҗәдә тоту.*
7. *Читтән коры сөт керү. Бәясе арзанрак булгач, заводлар коры сөткә өстенлек бирә.*

ХАЛЫК АВАЗЫ

3 март көнне сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист – **Сәрия МИФТАХОВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

Илдар Мөхәммәтҗанов

50 ел бергә. Нигә безгә бүләк юк?

Казан шәһәренең башкарма комитеты 50, 60, 70 ел бергә яшәгән гаиләләргә акча бирә. Ник авыл җирендә яшәүчеләргә андый бүләк юк? Гыйнвар аенда бергә яши башлавыбызга 50 ел булды, 5 бала үстердек. Үземә быел 75 яшь тула. Шөкер, мохтаҗлык юк, бөтен нәрсәбез дә бар. Тик күңел хөрмәт көтә.

МИФТАХЕТДИНОВА Зәмзәмия. Аксубай районы Иске Кыязлы авылы

Аксубай районының ЗАГС идарәсе:
– Һәр муниципалитетның башкарма комитеты түләүләрне үзе билгели. Безнең районда андый мөмкинлек юк. Ел саен юбилярларны хөрмәтләү кысасында Рәхмәт хатлары тапшырабыз. Аларны авыл җирлеге советы гаризасы белән яисә туганнары теләге буенча котлыйбыз.

Чит илдә укып буламы?

Кызым 10 нчы сыйныфта укый. Инглиз телен шомарту өчен, җәйге каникулда берәр программа буенча чит илдә укып булмыймы? Шунда яшәп, аралашып, ил культурасын өйрәнеп кайтыр иде.

РӘЗИНӘ. Казан

Мәгариф һәм фән министрлыгы матбугат үзәге:
– Министрлык тарафыннан мәктәп укучылары өчен андый программалар каралмаган. Студентлар, Хөкүмәт грантын отып, чит илдәге уку йортларына керә ала. Татарстан яшьләренә чит илгә китеп белем алырга «Алгарыш» гранты ярдәмгә килә. Әлеге программа республикабызда 2006 елдан бирле эшли. Студентлар үзләре белем ала торган уку йорты һәм аның партнер университетлары арасындагы студентлар алмашы программасы буенча да чит илгә китеп укып кайта алалар.

Стаж сатып алып буламы?

Сезнең газетада, пенсиягә иртәрәк чыгу өчен, стаж сатып алу турында укыдым. Иремә быел 60 яшь тула. Колхозчы ул, 39 елдан артык стажы бар. 1961 елда туганнарның армиядә хезмәт иткән вакыты стажга керми дип тә ишеттем. Без стаж сатып ала алабызмы?

ӘЛФИЯ. Тәтеш районы

Россия Социаль фондының Татарстан буенча бүлеге:
– Лаеклы ялга чыгу өчен, кешенең җитәрлек иминият стажы булырга тиеш. 2023 елда картлык буенча иминият пенсиясен алу өчен минималь стаж 14 ел тәшкил итә. Җитеп бетмәгән стажны сатып та алып була. Моның өчен Пенсия фондына гариза язып, тиешле акчаны түләргә кирәк. Сатып алынган стаж гариза язган көннән исәпләнәчәк. Моннан тыш, авыл җирендә яшәүче, эшләми торган һәм 30 елдан артык авыл стажы булган кешеләр пенсиясенә өстәмә түләүләр каралган. Узган елның 1 гыйнварыннан өстәмә түләүне авылдан күченгәннән соң да алырга мөмкин. Авыл пенсионерларына өстәмә түләү хокукы бирә торган стажны санаганда, колхоз, совхоз һәм башка авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә һәм оешмаларындагы эшләр исәпкә алына. Боларга терлекчелек, үсемлекчелек һәм балыкчылык керә.

Ләйсән САФИНА әзерләде

Кайтаваз

РӘШИТ ФӘТХРАХМАНОВКА РӘХМӘТ

Дөреслекне ачыкларга аптыраган бу заманда «ВТ»да кыю, олпат журналист Рәшит Фәтхрахмановның дөньяда, Россиядәге вакыйгаларга аерым тукталып, анализ ясап, иң мөһим сорауларга үз фикере белән шәрехләп язуы газета укучыларыбыз тарафыннан көтеп алына дип беләм. Аның мәнә шушы үзенчә аерым стильдәге язмалары өчен генә дә «Ватаным Татарстан» газетасына аерым язылып, өстәлебездә тотарлык. Әле яңадан ул «Фикер» астындагы күләмле күзәтүләрендә дөньякүләм икътисад, сәясәт, сәнәгать өлкәсендәге тормыш агышына да алып кереп, киң вә аңлаешлы мәгълүмат бирә. Икенче төрле әйткәндә, аны укысаң, берничә басманы актарып та тормыйсың – һәммәсенә иркен, аңлаешлы җавап аласың.
Әле яңарак кына хөрмәтлебез Рәшит Фәтхрахмановның 60 яшьлек юбилее уңаеннан аның хакында «ВТ»дагы кызыклы язмалардан укыдык. Үзем дә, ветеран журналист буларак, соң булса да, уң булсын дигәндәй, талантлы, тынгысыз, ихлас каләм иясен гомер бәйрәме белән тәбрикләп, аеруча «ВТ» укучыларын, гадәттәгечә, даими мәшһүр язмаларын, иманлы-көчле публицистикасын күрсәтеп-балкытып торырга язсын аңа!

Әсгать СӘГЫТДИНОВ, 1984 елдан СССР Журналистлар берлеге әгъзасы

Күрше хакы

9 миллион сум! Татарстанда милек хуҗаларының җылылык өчен дөрес түләмәве аркасында, җылыту өчен әнә шул сумманы яңадан исәпләгәннәр. Төп башына утыртмасыннар дисәгез, күпкатлы йортлардагы күршеләргә дә күз-колак булырга киңәш итә белгечләр. Акчаны янга калдырам дип, фатирда җылылык торбасын ябып куярга яратучы Вәли аркасында, күрше Галинең, үзе дә сизмәстән, чыгымнары арта, ди алар. Коммуналь хезмәтләр өчен белеп түлисезме?

Татарстан Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе Сергей Крайнов җылылык өчен исәп-хисап ясау тәртибенә ачыклык кертте. Моның өчен матбугат очрашуын махсус җыйдылар.

– Билгеле булганча, узган елның 1 декабрендә ил күләмендә, шул исәптән Татарстанда, коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр артты. Россия Хөкүмәте карары нигезендә тарифлар бер ел эчендә ике тапкыр күтәрелде. Декабрьдә республиканың күпчелек районнарында бәяләр 9 процентка артты. Шунысы да бар: бәяләр кабат 2024 елның җәендә генә артачак, – диде җитәкче.

Чүп өстенә – чүмәлә дигәндәй, кыш айларында түләү кәгазьләре болай да «тешли» башлый. Чөнки җылылык өчен түләү өстәлә, ә ул гомуми бәянең 60 процентына кадәр тәшкил итәргә мөмкин. Шуңа күрә гыйнварда декабрь өчен счет-фактура алган халык аптырашта калды.

– Гыйнвар аенда гына да халыктан коммуналь хезмәтләр өчен түләүләргә бәйле 622 мөрәҗәгать кабул иттек, – ди Сергей Крайнов. – Барлык очракларның яртысыннан да күбрәге җылылыкка туры килә. Татарстанда яшәүчеләр акчаны дөрес исәпләделәрме икән, дип борчыла. Без моңа бәйле 80нән артык мөрәҗәгатьне тикшердек инде. 17 очракта түләү кәгазендәге саннарның дөреслеккә туры килмәве ачыкланды.

Мәсәлән, башкаладагы берничә йортта урнаштырылган исәпләгеч җайланмаларның эшендә гаеп тапканнар. Ә менә Казанның Парин урамындагы 15 нче йортта ул, гомумән дә, ике ай тирәсе ватылып торган. Тик идарәче оешма вәкилләре моңа әллә ни аптырамаган. Кулланучыларга җылылыкны норматив буенча язганнар. Гәрчә мондый очракта, алдагы айларда кулланылган җылылыкның уртача күрсәткече исәпкә алынырга тиеш, дип аңлаттылар журналистларга «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат очрашуында.

– Җылылык өчен акчаны артык түләүчеләргә киләсе айларда яңадан исәп-хисап ясалачак. Гыйнвар өчен кулланучыларга 525 мең сум акча кире кайтарылачак, – диде Татарстан Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе урынбасары Светлана Заһидуллина.

Җылылык өчен исәп-хисап ясаганда башны бутаган тагын бер нәрсә бар. Ул да булса, намуссыз күршеләр.

– Бу – җылылык энергиясен исәпләүче шәхси җайланмалар урнаштырылган күпфатирлы йортларда яшәүчеләргә кагыла. Сүз, нигездә, соңгы елларда төзелгән яңа йортлар турында бара. Милек хуҗалары фатир сатып ала да, анда яшәмәгәч, акчаны янга калдырам дип, торбаларны ябып ук куялар. Тик гамәлдәге канун буенча болай эшләргә ярамый. Җылылык өчен акча ике төр күрсәткечтән чыгып исәпләнә. Ягъни без торакны җылыткан өчен генә түгел, ә җылылык энергиясе күпфатирлы йортка кадәр килеп җиткән өчен дә түлибез. Торбаны ябып куючылар гаебе белән, фатирга кадәр кермәгән җылылык гомуми кирәк-яраклар өчен тотылган энергия буларак исәпкә алына. Күпфатирлы йортта җылылык өчен түләү берничек тә нульгә тиң була алмый, чөнки җылылык йортка кадәр килгән бит инде, – ди Сергей Крайнов.

Милек хуҗаларының коммуналь хезмәтләр өчен дөрес түләмәве аркасында 9 миллион сумлык җылылыкны яңадан исәпләгәннәр әнә.

Бу хакта сөйләгәндә, Сергей Крайнов булган бер хәлне дә искә төшерде. Моннан дистә ел элек күпкатлы йортта яшәүче берәү: «Миңа гомуми җылыту системасы кирәкми, үземә шәхсән исәпләгечләр куйдырам», – дип (элек закон моны рөхсәт иткән, хәзер юк. – **Ред.**), торбаларны яптырган. Тик берни дә эшләмәгән. Кыш көне фатирда һава температурасы 14–16 градус тәшкил иткән. Салкынча, аның каравы акча түлисе юк. Бу кешенең әзенә тиз төшкәннәр.

– Фатирлар арасындагы диварлар җылылыкны үткәрә. Шуңа күрә күршеләр торбаларны «кыскан» саен, башкалар күбрәк җылылык тотарга мәҗбүр, – дип аңлатты җитәкче.

Бүген Казанда, Чаллыда һәм Түбән Камада җылылык энергиясен исәпләүче шәхси җайланмалар урнаштырылган 460 күпфатирлы йорт бар икән. Күршеләр, игътибарлырак булыгыз!

Эльвира ВӘЛИЕВА

vk.com

20 февраль | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР» 16+
10.00, 23.30 «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.40 «ДЕТЕКТИВ ӘНИ» 12+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45, 05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Әдәби хәзинә» 16+
19.00, 00.45 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
22.10 «Реальная экономика» 16+
00.20 «Каравай». Культура кряшен 6+
01.10 «Ком сәгате» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 16+
15.30, 20.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
19.00, 22.05, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
02.50 «Караоке татарча» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Сергей Марин, Игорь Петренко, Екатерина Вилкова. «НАЧАЛЬНИК РАЗВЕДКИ» (S) 16+
23.45 «Большая игра» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Светлана Смирнова-Марцинкевич, Алексей Комашко, Любовь Германова, Гёнюл Гезер, Арина Постникова, Дарья Горшкова. «МЕЖДУ НАМИ ГЛУБОКОЕ МОРЕ» 12+
23.45 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.25 Елена Яковлева. «КАМЕНСКАЯ» 16+
04.05 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Лыжный спорт. Кубок России. Фристайл. Биг-эйр 0+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 15.20, 22.35 Новости
07.05, 18.45, 21.45, 00.45 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00 Спецрепортаж 12+
10.25 Бокс. Bare Knuckle FC. Женские бои. Лучшее 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 «География спорта. Новороссийск» 12+
13.50 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 0+
14.25 Еврофутбол. Обзор 0+
15.25 «Громко». Прямой эфир
16.25 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Авангард» – «Барыс». Прямая трансляция
19.15 Хоккей. Чемпионат КХЛ. ЦСКА – «Торпедо». Прямая трансляция
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Торино» – «Кремонезе». Прямая трансляция
01.25 «География спорта. Новороссийск» 12+
01.55 Футбол. Чемпионат Германии 0+
03.55 Новости 0+
04.00 Еврофутбол. Обзор 0+
04.50 Спецрепортаж 12+
05.05 «Громко» 12+

НТВ

04.45 Детективный сериал «СТАЖЁРЫ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Остросюжетный сериал «ДЕЛЬТА» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Детектив «АКУШЕР» (S) 16+
22.00, 00.00 Остросюжетный сериал «МЕЛЬНИК» (S) 16+
00.25 Детектив «НЕВСКИЙ. ЧУЖОЙ СРЕДИ ЧУЖИХ» (S) 16+
04.30 «Их нравы» 0+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.20 «Давай разведёмся!» 16+
09.20 «Тест на отцовство» 16+
11.25 «Понять. Простить» 16+
12.30 «Порча». «Вампиры» 16+
13.00 «Знахарка» 16+
13.35 «Верну любимого» 16+
14.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «ПАВЛИН, ИЛИ ТРЕУГОЛЬНИК В КВАДРАТЕ» 16+
19.00 «СКВОЗЬ РОЗОВЫЕ ОЧКИ» 16+
23.05 «Голоса ушедших душ» 16+
23.40 «Порча» 16+
00.15 «Знахарка» 16+
00.45 «Верну любимого» 16+
01.15 «ИДЕАЛЬНАЯ ЖЕНА» 16+
04.25 «Понять. Простить» 16+
05.15 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

04.50 «РЫСЬ» 16+
06.30 «Легенды армии». Лев Доватор. 12+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 01.20 «ЛЕТЯТ ЖУРАВЛИ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «КОМИССАРША». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Оружие Победы. Щит и меч Красной армии». Документальный сериал. «Битва за Москву» 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал. «Шелепин против Брежнева. Борьба за власть» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «В ЗОНЕ ОСОБОГО ВНИМАНИЯ» 12+
02.55 «Вторая мировая война. Город-герой Севастополь». Документальный фильм 12+
03.20 «КОМИССАРША». 1-я и 2-я серии 16+

21 февраль | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР» 16+
10.00, 23.00 «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ» 12+
11.00 «Азбука долголетия» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ДЕТЕКТИВ ӘНИ» 12+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45, 05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Казаннан – Казанга» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Соотечественники» 16+
23.50 «Видеоспорт» 16+
00.15 «Соотечественники». Рашид Сафиуллин. Сталкер острова Свияжск 16+
00.40 «Каравай». Сад памяти. Цветы и травы Каюма Насыйри 6+
01.05 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Ком сәгате» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 16+
15.30 «Таяну ноктасы» 16+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.05, 22.10, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 Информационный канал 16+
11.30 Новости (с субтитрами)
12.00 Послание Президента РФ Владимира Путина Федеральному Собранию
13.00 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
22.00 «НАЧАЛЬНИК РАЗВЕДКИ». Многосерийный фильм (S) 16+
00.00 «Большая игра» 16+
01.00 «ЭДУАРД САВЕНКО. «В ПОИСКАХ ЛЮБВИ» 18+
02.25 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
12.00 Послание Президента РФ Владимира Путина Федеральному Собранию
13.00 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Светлана Смирнова-Марцинкевич, Алексей Комашко, Любовь Германова, Гёнюл Гезер, Арина Постникова, Дарья Горшкова. «МЕЖДУ НАМИ ГЛУБОКОЕ МОРЕ» 12+
23.45 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.25 Елена Яковлева в телесериале «КАМЕНСКАЯ» 16+
04.05 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Лыжный спорт. Чемпионат мира. Фристайл и сноубординг 0+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 16.55, 19.55 Новости
07.05, 14.25, 19.05, 22.00, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00 Спецрепортаж 12+
10.25 Смешанные единоборства. UFC. Генри Сехудо против Ти Джея Диллашоу 16+
11.05 Бокс. Bare Knuckle FC. Пейдж Ванзант против Рэйчел Остович 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 «Здоровый образ. Фигурное катание» 12+
13.50 «Магия большого спорта» 12+
15.50, 17.00 «ОДИН ВДОХ» 12+
18.05 «География спорта. Новороссийск» 12+
18.35 «Ты в бане!» 12+
20.00 Вечер профессионального бокса. Муслим Гаджимагомедов против Дениса Савицкого. Прямая трансляция
22.45 Футбол. Лига чемпионов. «Ливерпуль» – «Реал». Прямая трансляция
01.55 Футбол. Лига чемпионов. «Айнтрахт» – «Наполи» 0+
03.55 Новости 0+
04.00 «Третий тайм» 12+
04.30 Гандбол. ЧР 0+

НТВ

04.55 Татьяна Догилева. «БОМЖИХА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.20 Остросюжетный сериал «ДЕЛЬТА. ПРОДОЛЖЕНИЕ» (S) 16+
11.00 «Место встречи»
12.00 Послание Президента РФ Владимира Путина Федеральному Собранию
13.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Детектив «АКУШЕР» (S) 16+
22.00, 00.00 Остросюжетный сериал «МЕЛЬНИК» (S) 16+
00.25 Детектив «НЕВСКИЙ. ЧУЖОЙ СРЕДИ ЧУЖИХ» (S) 16+
04.35 «Их нравы» 0+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.15 «Давай разведёмся!» 16+
09.15 «Тест на отцовство» 16+
11.20 «Понять. Простить» 16+
12.25 «Порча». «С того света» 16+
12.55 «Знахарка» 16+
13.30 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Скажи, подруга» 16+
14.55 «СЕМЕЙНЫЕ ТАЙНЫ» 16+
19.00 «КАК ВЫЙТИ ЗАМУЖ ЗА ФРАНЦУЗА» 16+
23.00 «Голоса ушедших душ» 16+
23.35 «Порча» 16+
00.10 «Знахарка» 16+
00.40 «Верну любимого» 16+
01.10 «ПУАНТЫ ДЛЯ ПЛЮШКИ» 16+
04.10 «Понять. Простить» 16+
05.00 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «КОМИССАРША». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20 «В ЗОНЕ ОСОБОГО ВНИМАНИЯ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «КОМИССАРША». 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Оружие Победы. Щит и меч Красной армии». Документальный сериал. «Крушение «Цитадели» 16+
19.40 «Улика из прошлого». «Дело о тепловизорах. От Сталинграда до Соледара. Тайна двух окружений» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «ОТВЕТНЫЙ ХОД» 12+
01.05 «ДЕЙСТВУЙ ПО ОБСТАНОВКЕ!» 12+
02.10 «Энергия Великой Победы». Документальный фильм 12+
02.55 «Калашников». Документальный фильм 12+
03.20 «КОМИССАРША». 5-я и 6-я серии 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләгәне өчен Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры **Садыйков** Марат Наил улы (үлгәннән соң) Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **Пирогов ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Фәнни-педагогик эшчәнлегендәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Казан дәүләт энергетика университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры **Абдуллаҗанов** Эдвард Юныс улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар» өчен II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары **Гыйниятуллин** Искәндәр Әнвәр улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Илебезнең мәдәнияте һәм сәнгатен үстерүдәге казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле эшчәнлеге өчен «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе артисты **Төхвәтуллин** Рамил Чыңгыз улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Республикада физик культураны һәм спортны үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Стендка ату һәм ядрә белән ату буенча олимпия резервы республика спорт мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесе директоры **Демин** Сергей Константинович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Казан Кызыл байраклы Жуков орденлы югары танк командa училищесы» федераль дәүләт казна югары хәрби белем бирү мәгариф учреждениесенең чит телләр кафедрасы мөдире **Тубальцева** Валентина Александровна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Чаллы-Бройлер» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең кошларны тоту буенча эшчесе **Андриянова** Марина Геннадьевнага, «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Зеленодольск филиалы кош караучысы **Сабирова** Әнзия Ядкяр кызына **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе Алексеевск районы суд приставлары бүлекчәсе башлыгы – өлкән суд приставы **Кудελько** Светлана Петровнага **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

Динә
ГЫЙЛАҖИЕВА

ШӘМӘХӘ ТӨС КОТКАРА

Дөньяда ел саен 5 миллион кешегә эпилепсия диагнозы куела. Бу мәкерле чир күбрәк балалар һәм өлкәннәр арасында очрый, ди белгечләр. Вакытында чарасын күрсә, эпилепсия белән авырган кеше дә тулы канлы тормыш алып бара ала, дип ышандыра алар. Мондый диагноз белән яшәүчеләр тагын нәрсәләр белеп торырга тиеш? Эпилепсияне нинди билгеләр буенча танырга?

Төбәкара клиник-диагностика үзәгенең (МКДЦ) югары категорияле табиб-неврологы, медицина фәннәре докторы Татьяна ДАНИЛОВА белән шул хакта сөйләшәбез.

:: Эпилепсиянең яше бармы?

– Эпилепсия өянәге кеше гомеренең теләсә кайсы чорында пәйда булырга мөмкин. Шулай да ул балалар һәм өлкәннәр арасында ешрак очрый.

:: Эпилепсия ни сәбәпле пәйда була?

– Әлеге авыру нәселдән күчәргә мөмкин. Моңа баш миендәге үзгәрешләр дә йогынты ясый ала. Эпилепсия – инсульт, яман шеш, баш мие имгәнү нәтиҗәсе дә булырга мөмкин. Моннан тыш ул инфекция аркасында, организмдагы аутоиммун процесслар йогынтысында башлана ала.

:: Эпилепсиядән тулысынча котылып буламы?

– Аннан тулысынча котылып булмый. Бары тик андый чакта үзәккә үткән өянәкләрне генә туктатып торырга мөмкин. Моның өчен кеше көн саен махсус дарулар эчеп торырга тиеш. Аларны дөрес кулланган кеше 70 процент очракта эпилепсия өянәгеннән котыла ала. Даруларның файдасы тимәгәндә, эпилепсия нейрохирургия алымнары белән дәвалана. Бу очракта баш миенең эпилепсия өянәгә китереп чыгарган өлеше операция ярдәмендә алып атыла. Бу – бик катлаулы, җитди алым. Шуңа күрә аңа кешене кат-кат җитди тикшереп, белгечләр үзара килешеп, уртак фикергә килгәч кенә алыналар. Моннан тыш махсус алымнар ярдәмендә өянәкләрнең көчен, ешлыгын да киметеп була. Эпилепсиянең кайбер төрләре вакытында майлы ризыкларга өстенлек биреп, аксымны чикләүне күздә тоткан аз углеводлы кетоген диета да нәтиҗә бирә. Балаларга аеруча файдалы ул. Бу диета невролог тарафыннан гына билгеләнә. Эпилепсиядән интеккән кеше аны табиб күзәтүе астында гына тотарга тиеш.

vk.com

:: Балалар дигәннән, эпилепсия яшь организмны ни дәрәҗәдә үзгәртә?

– Вакытында чарасын күрмәсәң, баланың киләчәктә үсешендә тоткарлыклар пәйда булырга мөмкин. Аның хәтере начарлана, укыганда да проблемалар килеп чыгуы ихтимал.

:: Күзән җыерудан тыш, эпилепсия өянәген тагын нинди билгеләр буенча чамаларга мөмкин?

– Дөрестән дә, эпилепсиянең билгеләре күзән җыеру белән генә чикләнми. Кайбер очракларда кеше хәтта аңын да җуймаска мөмкин. Йөздәге мускуллар, бил, куллар билгеле бер ешлык белән хәрәкәтләнеп торса, аларны берничек тә контрольдә тотып булмаса, кеше бермәлгә тораташ булып катып калып, тирә-юньдәге бер нәрсәгә дә реакция белдермәсә, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Күзән җыерулар даими рәвештә кабатланган очракта да белгечкә күренү зарур. Аңны җуйганны көтеп торырга кирәкми.

:: Шәмәхә төс эпилепсия белән авырган кешеләрне тынычландыра, диләр. Бу, дөрестән дә, шулаймы?

– Шәмәхә төс 26 мартта билгеләп үтелүче эпилепсия белән авыручылар көне символы санала. Бу бәйрәмне эпилепсия белән авыручы 9 яшьлек Кессиди Меган исемле кыз уйлап тапкан. Язның бер көнен шәмәхә көн дип игълан итеп, яшьтәшләренә үзенең башкалардан берни белән дә аерылып тормавын, тулы канлы тормыш белән яшәвен исбатларга теләгән ул. Ни өчен нәкъ менә шушы төс дигәндә, әлеге төс эпилепсиядән интегүчеләрне тынычландыра, аларның нерв системасына уңай йогынты ясый, курку хисен юкка чыгара.

ЭПИЛЕПСИЯ ӨЯНӘГЕ ВАКЫТЫНДА КЕШЕГӘ НИЧЕК ЯРДӘМ ИТӘРГӘ?

✓ Әгәр кеше өянәк вакытында аңын югалтып егылган икән, аны иң элек янга яткырып, башын бераз аска төшереп, янга борып, муен турысын кысып торган әйберләрне чишәргә, бушатырга кирәк.
✓ Аның тирәсендә хәтәр, курыныч әйберләр булмаска тиеш.
✓ Эпилепсия өянәге вакытында кешенең авызын ачтырып, әйбер тыгарга, аңа су, дару эчерергә ярамый.
✓ Иң мөһиме – эпилепсияле кешегә ярдәм итәргә алынган зат тынычлык сакларга, хәвефләнмәскә, тиз арада «ашыгыч ярдәм» чакыртырга тиеш.

Тәмле дәва

Саулык, матурлык сагында

Тукымаларны тукландыра торган С витаминына, А, B_1, B_2, Д, Р витаминнарына бай булган лимон – күп авырулардан дәва. Ул косметологиядә дә даими кулланыла.

✓ **Тамак шешкәндә** телемләп киселгән лимонны авызга кабып суырасың һәм йотасың, моны сәгать саен кабатларга. Бигрәк тә лимонның кабыгы файдалы. Аны чәйнәгәннән соң, С витамины тамак төбендәге бактерияләрне үтерсен өчен, башка ризык капмый торасың.

✓ **Йөткергәндә** тигез күләмдә бал, лимон суы, шикәр комы алып кайнатасың да, өянәк башлангач, 1 аш кашыгы күләмендә кабып куясың.

✓ **Томау төшкәндә** борынга көнгә 5–6 тапкыр берничә тамчы лимон суы тамызасың.

✓ **Вирусларга каршы** чөгендер һәм лимон суы кушылмасы – иң яхшы чара.

✓ **Гипертониядән** интегүчеләргә тәүлеккә 3–4 тапкыр кабыгы белән ярты лимон ашау файдалы.

✓ **Баш авыртканда** лимон кабыгының ак элпәсен әрчисең һәм юеш ягы белән чигәгә куеп, берникадәр вакыт тотасың. Озакламый лимон кызарып чыгар, ә баш авыртуы бетәр.

✓ **Күңел болганганда** лимонның кабыгы белән йомшагы арасындагы ак элпә ярдәмгә килә. Косасы килгәндә, берәз гына баллы лимонлы су эчәсең һәм сохари ашыйсың.

✓ **Яхшы ишетү өчен** дә лимон кулланыла. Моның өчен көнгә 1/4 лимонның кабыгын ашау да җитә.

✓ **Күзән җыерганда** 10 көн дәвамында иртәкич аяк табанын лимон суы белән ышкыйсың. Суы килгәч, оек киясең.

✓ **Борын канаганда** борын тишегенә лимон суы сеңдерелгән мамык тыгасың. Кан нык ага икән, борын яфракларын бармаклар белән кысып, 3 минут тотасың. Бу вакытта маңгаегызга юеш салкын сөлге яки боз куясың.

Белә идегезме?

Мандаринның җимеше генә түгел, кабыгы да файдалы. Салкын тигәндә, бер аш кашыгы вакланган мандарин кабыгына бер стакан кайнар су салып, ярты сәгать төнәтеп, бал кушып эчәргә кирәк. Борынга томау төшкәндә, 2–3 мандарин кабыгына кайнар су салып, ингаляция ясасагыз да файдасы тимичә калмас. Атеросклероз вакытында исә 1 аш кашыгы вакланган мандарин кабыгына 1 стакан кайнар су салып, ярты сәгать төнәткәннән соң көнгә ике тапкыр ярты стакан күләмендә эчәргә кирәк.

Киңәш

ИШЕМИЯДӘН ДӘВА

Йөрәкнең кан белән тәэмин ителеше кимегәндә (ишемия), яңа әзерләнгән чөгендер суын 3 сәгать суыткычта тотыгыз. Шушы вакыт эчендә 125 мл ананас суы, 150шәр мл лимон, кишер һәм алма сулары әзерләгез. Шуннан, яшелчә һәм җимешләрнең суларын бергә кушып, 100 грамм бал өстәгез. Әзер төнәтмәне, ашарга 15 минут кала, көнгә 3 тапкыр берәр аш кашыгы эчегез. Йөрәгегез сәгать кебек эшли башлар!

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

«СӘЛАМӘТ ҮСЕНТЕНЕ ТУКЛАНДЫРМАГЫЗ»

Бакчачыларның, иртәрәк утыртсаң, уңышын да иртәрәк җыярсың, дигән фикердә торучылары петуния, сальвия ише вак орлыклы чәчәкләр, помидор, борыч, баклажанның иртә өлгерешле сортлары орлыкларын гыйнвар ахыры – февраль башында ук чәчте инде. Әмма күпчелек халык «бакча эшләре»нә чынлап торып тотыну өчен февральнең озын ялларын көтә. Шуны истә тотып, «Россельхозцентр» оешмасының Татарстан буенча филиалы үсемлекләрне саклау бүлеге әйдәп баручы агрономы Рәмзис ШӘРӘПОВтан бакчачыларга туфрак сайлау, гомумән, үсентеләрне карау-тәрбияләү серләре белән уртаклашуын сорадык.

– Үсентеләргә черемәле туфрак яки торф катнашмасы әйбәт. Тик шунысын истә тотарга кирәк: торф туфракның әчелеген арттыра. Шуңа күрә катнашмага береаз гына акбур яки известьташ өстәгез.

Орлык чәчү, үсентене күчереп утырту өчен туфракны, шулай ук савытын (искеләрен генә түгел, яңаларын да) зарарсызландырырга кирәк. Моның өчен марганцовка эремәсе (10 литр җылы суга 3 грамм марганцовка) әйбәт. Туфракка шушы эремәне сибәсе. Ә савытын дезинфекцияләү өчен, эремәне шунда салып, 30 минут тоту, шуннан соң гадәти су белән чайкап алу да җитә. Зарарсызландырганнан соң туфракның береаз кибүен көтәргә кирәк. Орлыкны чәчү тирәнлеге 1,5 сантиметрдан артмасын, шулай ук аннан ким дә булмасын. Үсү өчен иң кулай һава температурасы +25 градус чамасы.

Үсентеләргә суны туфрагының өске катламы кибүгә карап сибәбез. Моның өчен бүлмә температурасындагы су кирәк. Туфрагы юылмасын өчен, бер ноктасына гына түгел, ә бөтен өслеккә әкрен генә сибәсе. Савытның эчке стенасы буйлап сибүдән дә җайлысы юк.

Тукландыру. Үсентеләрне төрле ашламаларның чамасын белеп кенә тукландырырга кирәк. Тышкы «кыяфәте» нык булып, яфраклары – күе яшел, сабаклары шәмәхәрәк төстә икән, үсенте сәламәт дигән сүз. Мондый үсентеләрне ашламагыз. Юкса тукландыргыч матдәләрнең кирәгеннән артык булуы зыян гына салырга мөмкин.

Күчереп утырту. Бакчачылар кайбер очракларда инде тәрәзә төбендә үк үсентеләрне күчереп утырту ягын карый. Сәбәбе – үсемлекләрнең артык үсеп китүе яки чирле яфракларының пәйда булуы. Күчереп утыртканда, төп тамырының очын чеметеп

vk.com

кенә йолкып алыгыз. Тамырның буйга түгел, ә ян-якка тармакланып үсүе өчен шулай кирәк.

Күчереп утыртканнан соң, тизрәк яңарып, ныгып китсеннәр өчен үсентеләрне тукландырырга мөмкин. Шулай ук бер-ике көнгә җылырак урынга куеп тору киңәш ителә.

Ә инде теплицага чыгарып утыртырга ике атна кала, чыныктырырга кирәк. Моның өчен бүлмәдәге һава температурасының +15 °С чамасы булуы әйбәт. Ә инде утыртырга 5–7 көн кала, үсентеләрне ачык һавага чыгарып куясы.

Үсенте күчереп утыртканда стресс кичермәсен, яңа урынга тизрәк ияләшсен өчен микроашламалар (Гумат +7 «Здоровый урожай» һ.б.) һәм микробиоашламалар (НитроЗлак, Азолен, УниФос һ.б.) кулланырга киңәш ителә.

Укучы киңәше

Яшел витаминнан өзелмим

Мин пластик шешәләрдә суган кыяклары үстерәм. Бу, яшел тәмләткечкә ия булу белән беррәттән, начаррак (черү яки үсү билгеләре күренгән) суганнарны әрәм итмичә файдалану мөмкинлеге дә бирә.

Болай эшлим. 1,5–2 литрлы пластик шешә муенын 5 сантиметр чамасы киңлектә кисеп алам. Туфрак тутыру, су сибү өчен шулай җайлы. Аннан соң шешә тышында кечерәк суганнар сыярлык итеп, үткенрәк пычак белән, төбеннән 4 сантиметрга өстәрәк, берничә тишем ясыйм. Тишемнәр кыяк шуннан тышка үсеп чыга алырдай зурлыкта булырга тиеш. Кулны кисмәсен өчен, тишем кырыйларын шырпы яндырып яки кабызгыч белән береаз гына «өтеп» чыгам. Су җыелып тормасын өчен, шешә төбен берничә урыннан тишәм.

Суганның очын 1,5 сантиметр озынлыкта кисеп алам. Шуннан, киселгән очын тышка каратып, төшеп китмәслек итеп, шешәдәге тишеккә (3 см чамасы эчтә кала) урнаштырам. Шул рәвешле тагын ике-өч тишеккә суган утыртам. Шешәгә туфрак тутырып, кисеп алынган өлеше белән шешәне каплап куям. Су сибәргә кирәк булганда – ачам.

Суганга су сибәм һәм якты урынга куям. Суны артык күп салмыйм, юкса яшелчә черячәк. Суган кыяклары шиңмичә әйбәт үссен өчен тәрәзә төбендә эссе булмаска тиеш.

«Шешә-түтәл»гә бары тик бүлмә температурасындагы суны сибәм. Суык булса, кыяклар саргаячак. Яшел тәмләткечне ике тапкыр кисеп алгач, шешәне туфрак һәм суганнардан чистартып, яңа туфракка башка суганнар утыртам. Шулай итеп, беркайчан да суган кыягыннан өзелмим.

Галия САМАТОВА. Казан

Матурлык сере

Чәчкә – кышкы дәва

Кыш көне чәчләргә береаз гына яңа «сулыш» көрергә алырга кирәк. Суыктан, бүлмәдәге ясалма җылылыктан зыян күрә алар чөнки. Гөлҗимеш (шиповник), лимон һәм солы ярмасыннан ясалган маска чәчләрне кабартып, «терелтеп» җибәрәчәк, матур төс кертәчәк!

Эмальле савытка 1 стакан кайнап торган су һәм 2 аш кашыгы гөлҗимеш салабыз. «Су мунчасы»нда 30 минут тотабыз. Сөзәбез. 2 аш кашыгы төнәтмәгә 1 аш кашыгы лимон согы һәм 2 аш кашыгы солы оны (он юк икән, геркулесны кофе тарткыч аша вакларга мөмкин) өстәп, барысын бергә әйбәтләп болгатабыз. Катнашманы чәчкә сылап, 20 минут тотабыз да масканы юып төшерәбез.

Маскадан артып калган гөлҗимеш төнәтмәсен эчәргә мөмкин. Организм өчен генә түгел, чәчләр өчен дә бик файдалы ул.

Тәмле булсын!

«ГВАРДИЯ» САЛАТЫ

Роза ХИСМӘТУЛЛИНА рецепты

Ватанны саклаучылар көне хөрмәтенә һәр ел саен «Гвардия» салатын ясарга тырышам. Ир-атлар гына түгел, хатын-кызлар күңеленә дә бик хуш килә ул. Салатны азрак ясарга теләсәгез, күләмнәрне кечерәйтәсез.

Кирәк: *500 г сыер ите, 6 башлы суган, 5 аш кашыгы үсемлек мае, яртышар чәй кашыгы төелгән кара һәм кызыл борыч, 5 теш сарымсак, 20 мл су, 3 аш кашыгы томат пастасы, тәмена карап – хуш исле борыч.*

Итне – озынчарак итеп, суганны – ваграк кисәкләргә турап, сарымсакны изеп салабыз. Тәмләткечләрне барысын бергә салып болгатабыз. Салатны бизәргә кирәкми. Никадәр гадирәк булса, шуның кадәр яхшырак. Чөнки ир-атлар җитдилекне, гадилекне ярата.

ТӘМЛЕ АШ СЕРЛӘРЕ

✓ Шулпадагы дөге, изелеп, боткага әйләнмәсен өчен, ярманы башта, май салмыйча гына, табада кыздырып алырга кирәк.
✓ Аштагы борчак һәм фасоль, изелеп, юкка чыгып бетмәсен өчен, борчакны салганнан соң шулпа кайнап чыгуга, берәр чеметем чәй содасы өстәү әйбәт.
✓ Балык шулпасы, пешеп җитәр алдыннан, берничә телем алма салган очракта, искиткеч тәмле булачак. Балыкның күзләрен, саңакларын шулпага салмаска кирәк: алар әче тәм кертә. Шул ук вакытта шулпаны салмак кына утта пешерү әйбәт. Юкса ул болганчык булачак, балыгы да катырак килеп чыгачак.

Белеп тор!

Комнан арындырабыз

Яшел салат яфракларын, бигрәк тә үзебез үстергән салатны комнан арындыру җиңел эш түгел. Аны башта салкын суга салып 10 минут тотарга, шуннан соң кран астында юып алырга кирәк. Болай эшләгәндә, яфраклардагы комның бөртеге дә калмаячак.

Май чәчрәмәсен

Табага үсемлек мае салып, нәрсәдер кыздырганда, май чәчрәп, плитәне пычратырга мөмкин. Бер чеметем тоз сипкән очракта, май «тынычланачак» һәм тирә-юнь чиста калачак.

КҮҢЕЛ ЭШЕ

«Сәдака» гарәпчәдән тугрылык, әчкерсезлек дип тәрҗемә ителә. Дөрестән дә, Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен, чын күңелдән башкарыла торган гамәл бу. Шатлык килсә дә, борчуы булса да, сәдака бирергә тырыша адәм баласы. Сарланып, сәдака бирмәгән кеше кыямәт көнендә: «Раббым! Миңа тагын бераз гына булса да гомер бирсәң иде! Ул гомерем буена кешеләргә, ятимнәргә ярдәм итәр, сәдака бирер идем», – дип әйтер ди. Ул кемнәргә бирелергә тиеш? Ни өчен сәдака акчасына ризык сатып алырга ярамый?

Сәдакага бәйле сорауларыбызга Лаеш районындагы «Ихлас» мәчете имамы Мөдәррис ГЫЙМРАНОВ җавап бирде.

:: Сәдака кемнәргә бирелергә тиеш?
– Сәдака – ислам динендә бик дәрәҗәле әйбер. Аллаһы Тәгалә иман китергән, малларыннан сәдакага өлеш чыгарган кешеләрне олылый. Коръәни Кәримдәге «Бәкара» сүрәсенең 177 нче аятендә Аллаһы Тәгалә, ахирәткә, пәйгамбәрләргә, фәрештәләргә ышану турында әйткәннән соң, диннең гамәли өлешенә күчеп: «... яратуына карамастан, малларыннан туганнарга, мескеннәргә, ятимнәргә, мосафирларга сәдака бирүчеләр...» – дип дәвам итә. Бу хәдистән аңлашылганча, туганга бирелгән сәдака иң хәерлесе. Чит кешегә хәер биргәнче, башта туганнарың арасыннан мохтаҗлар юкмы дип карарга кирәк. Рәсүлебезнең бер хәдисендә: «Туганга бирелгән сәдака – ике әҗер. Беренчесе – сәдака бирү, икенчесе – туганлык җепләрен бәйләү әҗере», – ди. Икенче бер хәдисендә пәйгамбәребез: «Синең туганың синең сәдакаңа күбрәк лаек», – ди.

:: Коръән ашында сәдака өләшүнең билгеле бер тәртибе бармы? Аны хуҗа кеше генә таратырга тиешме, әллә бу кунаклар өчен дә мәҗбүри гамәл саналамы?
– Коръән ашында сәдака таратылырга тиеш дигән таләп юк. Халык шуны белеп торсын иде. Аш аның өчен үткәрелми. Өләшенгән очракта да, ул акча алышуга әйләнеп калмаска, мәҗлеснең асылын бозмаска тиеш. Коръән ашы дин, ислам таратылу, дәгъват урыны булырга тиеш. Бу Аллаһ юлында эшләнгән иң хәерле сәдака була. Хуҗа кеше истәлек буларак сәдака өләшеп чыкса, зыян юк. Әмма ашка килгән һәркемнең сәдака өләшеп йөрүенең кирәге юк.

:: Сәдака итеп бирү тыелган әйберләр бармы?
– Хәрам булган, динебездә тыелган әйберләрне сәдака итеп бирергә ярамый. Ризык мәсьәләсендә дә сак булырга кирәк. Балаларга сәдака итеп ризык бирәбез икән, аның составында желатин кебек динебез тарафыннан тыелган матдәләр булмаска тиеш. Кайчак кеше нинди акчадан сәдака биргәнен дә уйламый. Юкса, хәрам юл белән табылган акчадан бирелгән сәдака кабул булмаска да мөмкин бит. Шуңа күрә сәдака биргән вакытта чиста акчадан, хәләл юл белән табылган малдан гына өлеш чыгарырга кирәк.

:: Сәдаканы сорап алырга ярыймы?
– Әгәр кеше кыен хәлдә калган икән, ул очракта сәдаканы сорап алырга ярый. Дөнья булгач, төрле хәлләр була. Кеше операция кичерә, янгыннар чыга, хәвефхәтәргә тарый. Мондый чарасызлыкка дучар булганда, сәдаканы сорап алу рөхсәт ителә.

:: Әгәр бер кеше икенче кешегә: «Фәлән кешегә тапшырчы», – дип сәдака бирсә, шушы арадашчы аны ничек тапшырырга тиеш? Аның өстендә бурыч калмыймы?
– Әгәр сиңа кеше: «Фәләнгә тапшырчы», – дип сәдака тапшыра икән, син бу кешенең әманәтен аласың булып чыга. Син аны нәрсә генә булса да, үтәргә тиеш. Әманәтне үтәмәү – зур гөнаһ. Теге кеше янына баргач та: «Шул кеше сиңа сәдака тапшырып кушты», – дип яхшылап аңлатып бирергә тиеш. Бу очракта әманәт үтәлгән була. Сезнең өстә бернинди бурыч та калмый.

:: Сәдака акчасына ризык алырга ярамый, диләр. Бу дөрестән дә шулаймы?
Психолог игроманиягә дучар булучыларның билгеләрен дә санап күрсәтте. Иң элек бу – кызыксыну даирәсе кимү, элеккеге шөгыльләрнең кирәксезгә әйләнүе. Кеше ялгызакка әверелә, дус-ишләре белән азрак аралаша башлый. Уеннардан туктап торган арада борчылу, ярсу хисләрен кичерү – бу да шикләнергә сәбәп. Физиологик халәткә килгәндә, кәеф булмау, баш сызлау, йокысызлык, игътибарны туплауга бәйле кыенлыкларны әйтергә мөмкин. Төп билгеләрнең тагын берсе – зур уңышсызлыкларга очрап та, отышлы уеннарда катнашуны туктатырга тырышмау.

Нишләргә?

Белгечләр кешенең уеннарга бәйлелек стадияләрен дә аерып күрсәтә. Әйтик, беренче стадия «уен-дус» дип атала. Бу әле кешенең беренче тәҗрибәсе, комарлы уенга да ул бер кызык итеп кенә карый. Яңа танышулар, яңа хисләр чоры.

Икенче стадия – «уен-дошман». Уен кешенең күп вакытын һәм күп акчасын ала. Әҗәтләр барлыкка килә.

Өченче стадия – «уен-хуҗа». Куркыныч стадия санала, чөнки бу вакытта кешенең шәхси тормышында да проблемалар барлыкка килә. Бурыч йөге артканнан-арта, эш, гаилә, дуслар белән аңлашылмаучанлыклар килеп чыга. Кеше уеннарда катнашмаска тырышып караса да, уйнамыйча да тора алмый. Психологик халәткә йогынты ясарлык проблемалар да пәйда була.

Бәйлелектән интеккәннәргә ничек булышырга соң? Әлбәттә, бу очракта медицина белгечләренең ярдәменнән башка булмый. Гипноз, энә белән дәвалау, дарулар куллану кебек ысуллар бар.

Кеше үзенә ничек булыша ала дисәк, яңа хобби, кызыксынулар табарга киңәш ителә. Һәрчак терәк булырдай ышанычлы кешеләр булу бик мөһим (туган-тумачалар, шулай ук бәйлелектән интеккән кешеләр, мәсәлән).

Сан

- **295** млрд сум! Россия букмекерларының узган елгы кереме әнә шундый. Аз күрсәткеч түгел. «Букмекерлар рейтингы» сайты мәгълүматлары буенча, акча куеп, бәхет сынаучылар аудиториясе **36,55** млн кулланучыга кадәр җиткән.
- Комарлы уеннарда катнашучылар саны буенча беренче урында Гонконг тора. Икенче-өченче урыннарны АКШ һәм Канада бүлешә. Төрле мәгълүматлар буенча, Россиядә яшәүче халыкның **2** проценты тирәсе отышлы уеннарда катнашырга ярата.

Узган ел «Безопасность 2.0» мониторинг хезмәте казино һәм спорт уеннарына акча кую буенча кызыксыну аерууча зур булган төбәкләр исемлеген төзегән иде. 15 төбәк рейтингына Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләре, Мәскәү, Түбән Новгород, Свердловск, Новосибирск, Владимир, Воронеж, Волгоград, Ростов өлкәләре, Ставрополь, Краснодар крае, Башкортстан, Татарстан керде.

ХЫЯНӘТЧЕ ТҮГЕЛЛЕГЕН СИЗӘ ИДЕМ

15 ФЕВРАЛЬ КӨННЕ КАҺАРМАН МИЛЛӘТТӘШЕБЕЗ, СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 117 ЕЛ ТУЛДЫ

Бу җәһәттән матбугат чараларында күптән инде шагыйрь тормышының төрле мизгелләрен яктырткан язмалар күренә башлады. Яңалыклар да ачыла, фикер төрлелеге дә бар. Бер төркем татар журналистлары – газета-журналларның баш мөхәррирләре, Санкт-Петербургка барып, Муса Җәлилнең кызы Люция ханым белән дә очрашып кайтты. Алар арасында «Безнең мирас» журналы мөхәррире Ләбиб ЛЕРОН да бар. Без аның белән Төньяк башкаладагы хәлләр, аерым алганда, Люция ханым белән ничек күрешүләре хакында сөйләшеп алдык.

:: Ләбиб әфәнде, Санкт-Петербургка нинди җилләр ташлады? Ниләр күрергә бардыгыз?

– Без мондый форматтагы сәяхәтләрне җанисәп алу уңаеннан милләттәшләребез белән очрашырга, аңлату эшләре алып барырга дип башлаган идек. Башта Татарстан районнарында йөреп чыктык. Аннан ераккарак киттек. Башкортстанның татарлар яши торган төбәкләрен әйләнеп чыктык. Әстерханга, Оренбургка бардык. Йөри торгач, тагын бер максат барлыкка килде: ул да булса, татарның күз уңыннан төшеп кала язган күренекле кешеләрен барлау. Халык саны алу кампаниясе тәмамлануга карамастан, бу юнәлештә дә эшебезне дәвам итәбез. Киләсенә бүгеннән үк әзерләнергә, берләшергә, татар кимеде дигән хатаны төзәтергә кирәк. Йөргән саен, бу эшнең дөрес алып барылмавы ачыклана төшә. Күп җирдә татарларның ишеген шакучы да булмаган. Мәскәүдә дә булдык. Муса Җәлилнең кызы Чулпан апа белән дә күрештек. Ул да, килүче, сорашучы булмады, диде.

:: Муса Җәлилнең Санкт-Петербургта яшәүче кызы – Люция ханым белән дә очрашкансыз икән.

– Әйе, без ул хакта алдан ук уйланган идек. Җәлилнең өч баласы булганлыгы һәркемгә диярлек мәгълүм бит инде. Бу хакта матбугат чараларында да шактый басылып чыкты. Хәтерегездә булса, заманында язучы Нәбирә Гыйматдинова «Идел» журналында шагыйрьнең улы Альберт, кызы Люция турында да кызыклы язмалар биргән иде. Оренбургка барганда, без Муса Җәлилнең туган авылы Мостафага кердек. «Нишләп сезнең музейдә Җәлилнең балалары турында мәгълүмат юк, татар исемнәрен халыкка кайтарырга кирәк бит инде», – дип бик аптырадык. Җәлилнең туганы – Камал театры артисты Хәлил Әбҗәлиловны да искә төшердек. Аңа багышланган экспонатлар да күренми. Дөрес, заманында тегеяки бу сәбәпләр белән Люция ханымны да, улы Альберт абыйны да халык хозурына чыгарырга тырышмадылар. Әмма ул киртәләр җимерелде бит инде. Шуны аңлатырга тырыштык. Нәкъ менә шул чакта, Санкт-Петербургка барып чыксак, Люция апа белән очрашырбыз, дип тәгаенләп куйдык.

:: Сөйләшү ни хакында барды?

– Люция ханым башта 1955 елда әтисе акланган мизгелләрне искә төшерде. «Мин фортепианода уйнап утыра идем. Гөлшат апа Зәйнашева килеп керде. Синең әтиеңне аклаганнар, ул хыянәтче булмаган икән, диде. Мин тордым да, мин әтиемнең хыянәтче түгеллеген сизә идем, дидем. Шуннан соң мине Язучылар берлегенә чакырып алдылар. Трибунага чакырып сөйләттеләр», – диде. Белгәнебезчә, Муса Җәлилгә Ленин премиясе бирелә. Менә шул вакытта варислык мәсьәләләре калкып чыга. Берсен дә читтә калдырмыйлар. Акчаны дүрт кешегә – хатыны Әминә апага, балалары Чулпанга, Люциягә, Альбертка бүлеп бирәләр. Мәгълүм булганча, 1957 елда Мәскәүгә Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»н тапшырган Андре Тиммермансны чакыралар. Люция ханым ул вакытта Мәскәүдә укый торган була. Кунак белән күрешә. Андре Тиммерманс аңа: «Син әтиеңә нык охшагансың икән. Мусаны күргән кебек булдым», – ди.

:: Чыннан да шулаймы?

– Әйе, Люция апа кара чәчле, кара күзле, түгәрәк йөзле. Андре Тиммерманс аны бик ошатып кала. Әмма, ни кызганыч, башка күрешә алмыйлар. Ул Люция ханымга соңрак хат кына яза. Ул хаты әле дә саклана. Без дә укыдык.

:: Люция ханым әнисе Зәкия апа турында ниләр сөйләде?

– Зәкия Садыйкова Донбасс якларында туып-үскән. Шигырьләр язган. Менә шул иҗатка омтылыш кавыштыра да инде аны Муса белән. Зәкия шагыйрьгә, укып карарга дип, шигырьләрен җибәрә. Җәлил аларны ошата. Ике арада иҗат дуслыгы башлана. Соңрак фотосын соратып

Люция ханым әйтүенчә, әнисе Зәкия белән әтисе Мусаны иҗат кавыштыра.

ала да гашыйк була. Люция апа әйтүенчә, Муса аның әнисенә тугыз тапкыр тәкъдим ясый. Башта Зәкия апа кире кага, бик тугрылыклы булмас дип тә уйлана, күрәсең. Соңрак исә әбисе никах укыну оештыра. Шул вакытларда Мусага Мәскәүгә китәргә туры килә. Зәкияне дә үзе белән чакыра. Әмма ул, башта үзең урнаш әле дип, китмичә тора. Күпмедер вакыт үткәч, Җәлил Әминә белән танышып өлгерә. Зәкиягә: «Синең Мусаң башкалар белән», – дип ирештерәләр. Горур хатын булган, күрәсең. Шул сүз җитә кала, Люциягә көмәнле булса да, араны өзә, артистлар белән Ташкентка китеп бара. Муса аның мондый хәлдә икәнлеген белмәгәндер дип уйлыйм. Бала Үзбәкстанда дөньяга килә. Кызына 4 ай 5 көн дигәндә Зәкия апа Казанга, Яңа бистәдәге әти-әнисе янына кайта. Җәлил, баласы барлыгын ишетә, күрәсең, тиз арада килеп җитә. Әбисе сөйләвенчә, бик яратып, баланың борынын кысып тота. Әмма ул Әминә ханым белән тормыш корып өлгергән була инде. Соңрак Зәкия апа да кияүгә чыга. Ире бик көнләшә, Люция апаны да кыерсыта. Зәкияне шигырь язудан да туктата, төн утырып язган шигырьләрен мичкә яга. Казанда Опера театры ачылгач, Муса Җәлилне әдәбият бүлеге мөдире итеп Казанга күчерәләр. Ул Зәкиягә: «Кызымны миңа бир. Сеңлем Хәдичә карашыр. Аны кыерсытмасыннар иде», – дип өзгәләнә. Шул сүзләрне әйткәндә, Мусаның күзләреннән яшь бөртекләре тәгәрәп төште, дип искә ала торган була әнисе. Тик ана үзенең баласын биреп җибәрә алмый инде. Мәгълүм хәлләрдән соң Зәкия апаның тормышы тагын да авырая. Ире башта: «Сатлыкҗан баласын ашатып ятам», – дип битәрли. Җәлилгә Герой исеме бирелгәч, Люциягә булган игътибардан көнләшә башлый.

:: Люция апаның тормыш юлы нинди юнәлеш алган?

– Ул Казанда үсә. Мәктәптә укыган вакытта ук фортепианога тартыла, музыка мәктәбендә укый. Әтисе дә, минем кызымны музыкага өйрәт, дип әйткәндер дип уйлыйм. Муса үзе дә бик шәп уйный торган була бит. Люция апа башта музыка училищесында, аннан Бөтенсоюз кинематография институтында белем ала. Күренекле композиторлар Мирсәет Яруллин, Фасил Әхмәтов, Ренат Еникеев белән якыннан таныш була. Алар өчесе дә «Люция» дигән җыр язалар. Кем белә, бәлки, гашыйк булып йөргәннәрдер. Җырларга килгәндә, Муса Җәлил сүзләренә Җәүдәт Фәйзи дә берничә көй язган. Шул исәптән «Кызыма» дигән җырны да. Баксаң, алар Оренбургта чагында бер урамда яшәгәннәр икән. Люция апа бу җырны үзенә багышлангандыр дип тә уйлый. Яңа Бистәдәге йортның чормасында Муса Җәлилнең әнисенә язылган 15ләп хаты да сакланып кала. Люция апа безгә аларның берсен генә күрсәтте. Игътибар булмауга карамастан, ул әтисе турында истәлекләр җыюдан туктамый. Бу 24 катлы йортның 16 нчы катында урнашкан фатирына кергәч тә сизелә. Бик чиста, саф өй. Китап киштәсендә әтисенең бик күп китаплары урын алган. Муса Җәлилгә булган хөрмәт күренеп тора. Без килгән төшкә махсус әзерләнгәндер дип уйламыйм. Очрашудан бик канәгать калды. Рәхәтләнеп сөйләштем, диде. Рәхмәтләрен җиткерде. Мин үзем дә аңа әтисе турында язмалар басылган журналлар бүләк иттем.

Люция ханым 1981–2002 елларда Казан мәдәният институтында укыта. Санкт-Петербургта режиссерлык эшен ташламый. Кызы Лилиан да кинофильмнарда уйный, укыта, татарча белә, сөйләшә. Ире Гурам Наврозашвили Казанда театр рәссамы булып эшли.

Люция ханым Казанга «Моабит дәфтәрләре»нең ничек кайтуы турында документаль фильм төшерергә хыялланган. Төрле сәбәпләр белән барып чыкмаган. Икесенең дә Муса Җәлилнең туган авылы Мостафага кайтып, күреп киләселәре килә. Быел бергәләп барып килербез, дип вәгъдә иттек. Бик шатланышып, көтеп калдылар. Шагыйрьнең оныгы Лилиан да бабасы турында кино төшерергә тели. Кем белә, бәлки, бу зур эшнең башы шушы Мостафа авылына кайтып китү булыр. Берочтан Оренбург шәһәрен дә күрсәтербез дип торабыз. Муса Җәлил анда шактый яшәгән, аңа бәйле урыннар бик күп.

:: Муса Җәлилнең балалары үзара аралашып яшиме?

– Люция апа, Чулпан белән мөнәсәбәтләребез әйбәт, диде. Ә Альберт абый белән алар бик аралашып, дустанә мөнәсәбәтләрдә яшәгәннәр. Гаилә альбомында бергә төшкән фотолары да саклана.

:: Университетта укыганда, төркемдәш егетләр хәрби әзерлек дәресләренә йөри һәм, безне Муса Җәлилнең улы укыта, дип мактанышалар иде. Без бит бер чорда укыдык. Сез дә беләсездер?

– Әйе. Альберт абый да Муса Җәлилгә бик охшаган иде. Сөйләгәннәре дә хәтердә калган. Ул кечкенәдән очучы булырга хыяллана. Тик, сәламәтлеге какшап китеп, күккә күтәрелә алмый. Саратовта хәрби училищены тәмамлагач, 12 ел Германиядә хезмәт итә. Альбертның әнисе Рауза ханым Хисмәтуллина Камал театры актрисасы булган. Альберт абый туганнан соң ул, икенче кешегә кияүгә чыгып, Украинага китә. Биш елдан соң Ижаудагы туганнары янына кайталар. Күңелдә бер үкенеч бар инде. Ничә еллар очрашып йөреп, тормышы турында тәфсилләбрәк сорашмаганбыз. Бәлки, күп нәрсәләр турында белгәндер ул.

:: Әле менә «Безнең мирас» журналының соңгы санын карап утырам. Татарстан телевидениесенең элеккеге дикторы Рөстәм Нәбиуллин яңа экспонат – Муса Җәлилнең култамгалы «Алтынчәч» китабын китергән икән. Ул еллардагы хроникадан кадрларны туктатып төшергән сурәтләрен дә тапкан. Тагын ниләр эшләргә, ниләр табарга хыялланасыз?

– Альберт абыйның кабер ташы кыйшайган. Башта шуны төзәтеп кайтырга исәп. Зәкия апаның шигырьләрен табып булмасмы дип уйлыйбыз. Муса Җәлил уңай бәя биргәч, алар тәгаен яхшы булырга тиеш бит инде. Таба калсак, журналда укучыларыбызга да тәкъдим итәр идек.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ҮЧТЕКИ-ҮЧТЕКИ, АКЧА САНЫЙ КЕЧТЕКИ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Сабый үз ризыгы белән туа

Хатын-кызлар арасында сораштыруны иseме билгеле булган имиииятләштерү оешмасы үткәргән. Анда 25–45 яшьлек гүзәл затлар катнашкан. Сораштырудан күренгәнчә, бүген бала үстерүгә бәйле чыгымнар ай саен уртача 38 мең сум тәшкил итә икән. Баксаң, хатын-кызларның күбесе, тәгаен әйтсәк, 72 проценты бәби алып кайтырга дип алдан бернинди дә мая тупламый. Кем белә, бәлки, әзерлек эшләре әтиләр җилкәсендә булгандыр. Монысын әйтмәгәннәр. Әни булырга җыенучыларның 20 проценты алдан аяк киенсә, 8 проценты бала үстерүгә бәйле чыгымнарга кредит алырга туры килүен дә яшермәгән.

Түбән Камада яшәүче ике бала әнисе Рәминә Сәлахиеваны бу саннар белән генә куркытып булмый. Аның үз хисап кенәгәсе бар.

– Мин әни булырга алдан ук әзерләнүчеләр рәтеннән, – ди ул, үзенә сәерсенеп караучылар күп булуын алдан ук кисәтеп. – Кечкенәдән үк «копилка»га акча җыярга яратам. Акчаны сак тотам, әрәм-шәрәм итмим. Дүрт һәм сигез яшьлек ике кызыбыз бар. Гаилә бюджеты уртак. Бөтен чыгымнарны, шул исәптән, балаларга киткәнен дә теркәп барам. Мәсәлән, дүрт яшьлек балама туганнан алып бүгенгә кадәр 1 миллион 400 мең сум акча тотканбыз. Бала караваты, коляска, нәниләр өчен урындык, кышкы кием-салым ише кирәк-яракларның олысыннан калганлыгын да истә тотарга кирәк. Иң зур чыгымнар бала тууның беренче елына туры килә, бишектәге балага ел дәвамында 600 мең сум тирәсе акча киткән. Аена 2,5–3 мең сумлык «памперс» кына сатып алганбыз. Сабыйлар өчен яшелчә, җиләк-җимеш измәләре дә шактый кыйммәт. Бала табынына айлык чыгымнар 2 мең сум чамасы тәшкил иткән. Кызымда аллергия булгач, өйдә ясаган алма боткалары килешмәде. Кибетнекен ашаттык. Өч яшь тулгач, чыгымнар тагын күбәеп китте. Кызым дәүләт бакчасына йөри. Җыр, рәсем түгәрәкләренә яздырдым. Бакчага – аена 4 мең сум, түгәрәкләргә тагын 4 мең сум тирәсе кирәк. Ике балага аена 20–25 мең сум акча китә. Бу – мәҗбүри чыгымнар гына әле. Былтыр, мәсәлән, балалар бүлмәсенә 200 мең сумлык ремонт ясаттык. Җәй көне дүрт кешелек гаиләбезгә 230 мең сумга юллама алып, диңгезгә барып кайттык. Боларның барысын да исәпкә алсаң, бала бик кыйммәткә төшә, әлбәттә.

Сәлахиевлар гаиләсендә акча өчен берьюлы өч тартма бар.

Мәҗбүри чыгымнар тартмасы. Монда ипотека түләве, ашау-эчүгә һәм көнкүреш кирәк-яракларына киткән акча, коммуналь түләүләр, бензин, кәрәзле элемтә, интернет (балаларга бәйле чыгымнар аерым. – **Ред.**) өчен түләү керә. Җәмгысы аена 40 мең сум чамасы. Ел фасылына карап, чыгымнар да бераз үзгәрә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Запастагы акча тартмасы. Ай саен 5 мең сум дарулар сатып алу, машина төзекләндерү кебек көтелмәгән чыгымнар өчен саклана.

Көндәлек чыгымнар тартмасы. Бала яңа уенчык сораса, әти кешенең берәр кайда ял итеп кайтасы килсә, я әнинең кибеттәге күлмәккә күзе төшсә, акчаны әнә шул тартмадан аласы. Моның өчен гаилә бюджетында аена 5 мең сум акча каралган. Акчаны тиенена кадәр тотып бетерү мәҗбүри түгел.

Шул рәвешле, гаиләнең айлык чыгымнары 70 мең сумга кадәр җитәргә мөмкин. Мая җыярга хәл калмый, ди Рәминә. Хәер, бу аңлашыла да.

775 мең сумлык ярдәм

– Балага аена 38 мең сум акча тота алган гаилә бик бәхетле, – ди социолог Светлана Ивакина. – Рәсми саннарга караганда, илдә яшәүче ярлыларның 82 проценты – кимендә бер баласы булган гаиләләр. Бәби тугач, гаиләнең кереме ким дигәндә 25 процентка төшә. Татарстанда уртача хезмәт хакы 50 мең сум тирәсе тәшкил итсә дә, бу хастаханәдәге уртача һава температурасы кебек кенә, билгеле. Авылларда яшәүчеләрнең, мәсәлән, балага бу кадәр акча тотарга мөмкинлеге юк. Тик мәсьәләнең икенче ягы да бар: салада чыгымнар ул дәрәҗәдә зур түгел, мондый ихтыяҗ да юк. Ә менә әти-әниләрнең күпчелеге балага киткән акчаны гомумән санамый. Киресенчә, сабыйны иң кәттә бала арбасына салалар, аны төрледән-төрле түгәрәкләргә йөртәләр. Бишектә яткан сабыйга фатир сатып алып куялар. Сер түгел, килачәккә иң яхшы инвестиция ул – бәхетле, сау-сәламәт һәм уңышка ирешкән бала. Бу хакта сөйләгәндә, дәүләттән күрсәтелүче ярдәм чаралары турында да онытырга ярамый.

БАЛА ТӘРБИЯЛӘҮЧЕ ГАИЛӘЛӘРГӘ ТӨП ЯРДӘМ ЧАРАЛАРЫ

Беренче балага ана капиталы	586,9 мең сум
Икенче балага ана капиталы (беренче балага алынмаган булса)	775,5 мең сум
Икенче балага ана капиталы (беренче балага алынган булса)	188,6 мең сум
Бала тугангa бердәм пособие	22,9 мең сум
Яшь ярымга кадәр бала тәрбияләгән өчен пособие (минималь күләме)	8,5 мең сум
Йөкле хатын-кызларга һәм 17 яшькә кадәр бала тәрбияләүче аз керемле гаиләләргә бердәм пособие (минималь күләме)	5,9 мең сум

Балаларны кайгырту – илдәге өстенлекле юнәлешләрнең берсе. Ул җитәрлек дәрәҗәдәме-юкмы: монысы инде – икенче мәсьәлә.

Балалы гаиләләргә ярдәм чараларын Дәүләт хезмәтләре порталыннан карадык. Анда йөклелек чорыннан алып 18 яшькә кадәр ул-кыз үстерүчеләргә 16 төрле ярдәм чарасы тәкъдим ителгән.

Агымдагы елның иң зур яңалыгы – 1 гыйнвардан гамәлгә кергән яңа бердәм пособие. Ул йөкле хатын-кызларга һәм 17 яшькә кадәр бала тәрбияләүче аз керемле гаиләләргә кагыла. «Бердәм пособие аз керемле гаиләләргә моңа кадәр гамәлдә булган ярдәм чараларын берләштерде. Болар – гаиләдә беренче балага 3 яшькә кадәр түләү, 3 яшьтән алып 8 яшькә кадәр һәм 8 яшьтән алып 17 яшькә кадәр балаларга пособиеләр һәм йөклелек буенча айлык акча. Яңа пособие керем дәрәҗәсе Татарстанда билгеләнгән яшәү минимумыннан кимрәк булган гаиләләргә бирелә. Исегезгә төшерәбез: республикада әлеге күрсәткеч 12219 сум тәшкил итә. Бердәм пособие билгеләгәндә гаилә әгъзаларының керемнәре, милке һәм рәсми эш урыннары исәпкә алына», – диелә Социаль фондның Татарстандагы бүлеге хәбәрендә.

2023 елның 1 февраленнән икенче балага ана капиталы (беренче балага алынмаган булса) 775 мең сумга җитте. Татарстанда ана капиталына ия булган гаиләләрнең 86 проценты акчаны яшәү шартларын яхшыртуга юнәлткән. Россия Дәүләт Думасы депутатлары әлеге акчага машина сатып алырга рөхсәт итмәкче. Әнә шул эчтәлектәге закон проектын тәкъдим иткәннәр. Яңалык гамәлгә керсә, ана капиталына күп дигәндә сигез урынлы, фәкать үзебезнең илдә җитештерелгән яңа машина сатып алып булачак. «Бала машинасы»н өч ел сатарга да ярамый. Яңалыкны хуплаучылар да күп. Ил Хөкүмәте каршындагы Финанс университеты галиме Александр Сафонов әйтүенчә, күптән кирәк иде.

– Гаиләдә машина булса, өйдән ерактарак урнашкан яхшырак эшкә йөрү мөмкинлеге барлыкка киләчәк. Димәк, балаларның матди хәле тагын да яхшырачак. Өстәвенә балалар бакчасына, мәктәпкә йөртү дә җиңеләячәк, – дигән ул.

Рульдә йөрүче әниләр саны артырмыюкмы, монысын вакыт күрсәтер.

Фикер

Артем КУЗНЕЦОВ, Татарстан Иҗтимагый палатасы әгъзасы, «Татарстанның күпбалалы гаиләләре» төбәкара иҗтимагый оешмасы рәисе:

– Күпбалалы гаиләдә сабыйлар бер-бер артлы туа. Шуңа күрә әниләрнең күбесе хуҗабикә буларак өйдә утыра. Гаиләне бер әти туендыра. Бала саен 38 мең сум акчаны эшләп тә табарга кирәк бит әле. Бер урында гына хезмәт кую аз, билгеле. Күп кенә әтиләр буш вакытта, ял көннәрендә өстәмә эш башкарырга мәҗбүр. Фатирларга ремонт та ясыйлар, таш та ташыйлар. Бөтен гаиләләрдә дә диярлек ипотека булуын да онытмагыз. Керемнәрнең күп өлеше кредит түләүгә китә. Татарстанда мәктәп яшендәге балаларны бушлай түгәрәкләр, спорт секцияләре белән тәэмин итү күрсәткече – 115 процент. Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы китерәгән саннар бу. «Ничек алай була соң?» – дип сорагач, кайбер балалар ике-өч бушлай түгәрәккә йөри, дип аңлаттылар. Димәк, шартлар тудырылган. Тик икенче мәсьәлә бар. Мәсәлән, минем кызым бушлай рәсем түгәрәгенә йөри. Әмма буяу, пумала ише бөтен кирәк-яракны, без, әтиәниләр, сатып алабыз. Бу – өстәмә чыгым дигән сүз. Кызганыч, гаиләдә балалар саны күбрәк булган саен, ярлылар саны да арта. Ә пособиеләргә килгәндә, аларны үзегез күреп торасыз. Мәсәлән, гаиләнең кереме яшәү минимумына кадәр тулып бетми икән, аңа шул күрсәткечкә җиткәнче генә акча өстәп түлиләр. Артыгын беркем дә бирмәячәк. Дөрес, керем дәрәҗәсенә карап, ана капиталын тотарга рөхсәт итттеләр. Тик бу да ул кадәр күп акча түгел. Кыскасы, икътисадый шартлар гаиләләрне тәэмин итеп торырга җитми. Ничек кенә булмасын, һәркем үз тормышы өчен үзе җаваплы дип саныйм.

Җаным җәл түгел сиңа

Гел әниләр дә, әниләр, ә әтиләр кайда соң, диярсез. Баксаң, илдәге гаиләләрнең нибары 29 процентында гына балага киткән чыгымнарны әти кеше карап-тикшереп тора икән. «ВТ» хәбәрчесе барлап чыккан таныш-белешләр арасында бала бүген мәктәптә ничә сумга ашаган, бакчадагы бию түгәрәге ничә сум тора – тәгаен белүче әти табылмады. Шуңа күрә үпкәләштән булмасын. Аның каравы балага киткән чыгымнар «капчыгы» гаилә башлыгы җилкәсендә. Сораштыруда катнашкан хатын-кызларның 20 проценты гына: «Әлеге төр чыгымнарны ирем белән бертигез дәрәҗәдә каплап барабыз», – дигән. Менә шундый хәлләр.

Татарстанның атказанган артисты Ландыш Нигъмәтҗанова әйтүенчә, балага киткән акчаны исәпләү, гомумән дә, дөрес түгел.

– Мин азык-төлек кибетендә күпме акча киткәнне дә белмим. Чынлап, андый исәп-хисап ясыйсым да килми. Кирәк әйберне барыбер сатып аласың инде аны, бәясенә карап тормыйсың. Бигрәк тә, балаларга кирәклесен. Баланы акча белән үлчәргә кебек килеп чыга. Моны дөрес түгел дип саныйм. Мин дүрт балама ничә сум акча киткәнне белмим. Күпме генә тотылса да, без риза. Алар өчен, алар хакына яшибез бит. Балаларга берни җәл түгел, – ди җырчы.

Эльвира ВӘЛИЕВА

«ВТ» ГАЗЕТАСЫНЫҢ 105 ЕЛЛЫГЫНА МАХСУС ӘҢГӘМӘ.
БЕЗНЕҢ КУНАК – ТАТАРСТАННЫҢ ҺӘМ РОССИЯНЕҢ ХАЛЫК АРТИСТЫ РАВИЛ ШӘРӘФИ

«ТАТАР – ТАБИГАТЕ БЕЛӘН АРТИСТ»

Халыкны тәрбияләргә кирәкме? Ил-көндәге вазгыять мәдәният-сәнгатькә ничек тәэсир итә? Бу өлкәдә югалтулар күбрәкме, әллә табышлармы? Болар һәм башка мәсьәләләр турында Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Равил ШӘРӘФИ белән сөйләштек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Равил абый, сугыш чоры баласыннан иң әүвәл, авыр чакта таянычны кайдан табарга, дип сорыйк әле.

– Хәзерге вазгыятьтә кая таянырга икәнен мин үзем дә белмим шул... Әйе, сугыш чоры безнең бала вакытка туры килде. Сабыйлык белән аның авырлыгын бик сизмәдем. Балачак хатирәләрендә мин үземне гел өйдә дип хәтерлим. Күбрәк кыш айлары хәтердә. Күрәсең, абыем белән апам мәктәптә сабак укыган, мин өйдә бозау, сарык, кәҗә бәтиләре белән көнне үткәргәнмен. Бер абый белән әти сугышта. Әни исә көне-төне фермада. Әмма аның эштән кайткан мизгелләрен мин ачык хәтерлим. Зарыгып көтелгәндер. Ә менә җәй айлары истә калмаган. Җиңү бәйрәменә кадәр җәй көннәре бөтенләй дә истә юк. Чөнки мин урамга чыгып киткәнмен дә рәхәтләнеп йөргәнмендер инде. Ә өйдә ялгыз утыру, шул хиснең авырлыгы күңелгә онытылмаслык булып кереп калган.

Авыр вакытта нәрсәгә таянырга икәнен әйтә алмыйм... Барый Әшрәпов дигән артист бар иде. Авырганда хатын аның янына хастаханәгә барып йөрде. Шул, Ходай, җан тынычлыгы бир, дип теләп торган булган. «Нәрсә икән соң ул җан тынычлыгы?» – дип гаҗәпләнә идем, ди. Менә хәзер аңлыйбыз инде күңел тынычлыгының нәрсә икәнен. Ул тормышта төп әйбер икән. Минем аны эзләп таба алганым юк әле. Дөрес, намаз уку беркадәр тынычландыра.

:: Бер әңгәмәдә, мәчетләргә йөрмим, дип тә әйткәнсез.

– Мәчетләргә йөрмим шул. Гает намазына барып, бик үк матур булмаган күренешкә тап булганым бар. Миннән алдагы бер картның оекбашы шулкадәр пычрак иде. Юкса татар карты. Күңелем кайтты. Аллаһ йортына пакь киемнән йөрергә кирәк. Аннан соң мәчетләрдә хәзер татарлар бик аз. Мәчеттә укуның сәбәбы күбрәк, дисәләр дә, мин өйдә укырга булдым.

:: Ничек уйлыйсыз, без күндәм халыкмы?

– Бик күндәм.

:: Ниндидер буыннардан соң үзгәреш булыр дип уйлыйсызмы?

– Өметем бик юк. Бездә тәлинкә тоту көчле. Менә минем бер фикер белән бүлешәсем килә. Дөньяда җитәкчеләр бар. Ил җитәкчеләре, оешма җитәкчеләре. Бездә хәзер һәр җитәкче берүзе генә акыллы. Аларның киңәшчеләре юк. Киңәш бирергә куркалар. Җитәкче ялгышса да, аңа каршы төшәргә куркалар. Миннән сорасалар, мин куркып тормас идем. Ә бит элекке заманда патшалар шамакайлар тотканнар. Шамакай дөрес фикерне патшага курыкмыйча җиткергән. Шуңа күрә җитәкчегә үзе янында һич югында акыллы бер дурак тотарга кирәк. Киңәшсез эш таркалыр, ди зирәк халык. Ил белән киңәшергә кирәк. Минем республика җитәкчесенә дә киңәшемне әйткәнем бар. Хәзер дә киңәш бирер идем, әгәр аңа чыгу юллары булса.

:: Җанисәп нәтиҗәсен ничек кабул иттегез?

– Мин аны шулайрак булыр дип фаразлаган идем инде. Аны күпме булуына карап түгел, күпме кирәк дигән принциптан чыгып эшлиләр. Бу җәһәттән татарларга да үпкәм бар. Үз балаларын күрәләтә урыслаштыралар. Әнә безнең язучыларның балалары урыс шагыйре, урыс прозаигы булып китә. Үзеннең баланы да татарча өйрәтмәгәч... Оныгым Шадәны мисалга китерим әле. Ул хәзер Мәскәүдә, гел урыс мохитендә. Ләкин татарча менә дигән белә. Мәскәүдә яшәсә дә, безнең белән бервакытта да урысча сөйләшкәне юк. Шулай булгач, тәрбия гаиләдән килә. Монда кемгәдер сылтыйсы юк.

:: Соңгы вакытта театрлар тарихи әсәрләргә ешрак мөрәҗәгать итә. Камалда «Мөһаҗирләр» чыкты, тинчуринлылар «Идегәй»гә алынды. Кемдер, театрлар яңадан туксанынчы еллар күтәрелешен кичерә, дип тә әйтә.

– Театрларда ниндидер күтәрелеш сизмим. «Идегәй»не алсак, бердән, хәзерге тамашачыга аңлаешсыз элеккеге тел белән куелган. Тамашачы кулына тәрҗемә буклетын тотып утырырга мәҗбүр. Ярый, мин әле иске татар телен аңлыйм, гади тамашачы нишләсен? Анда мин Идегәйне күрмәдем. Тузан, төтен, чыбыркы шартлатуыннан кала, бернәрсә истә калмады. Элек тә әйткәнем бар, хәзер дә кабатлыйм: мин яшь чакта театр шушы хәлдә булса, артист булмас идем. Мин – психологик театр вәкиле. Хәзер кирәкмәгәнгә сикерәләр, тиктомалдан бии башлыйлар – бернәрсә аңлашылмый. Әле шуны аңларга кушалар. Ә нишләп мин, залда утыручы, бу нәрсә әле, дип баш ватарга тиеш? Баш катырмыйча гына аңлатып кара син аны.

:: Менә сез нинди генә рольләр башкарсагыз да, халык күңеленә Әҗәл булып кереп калдыгыз. Урамда Әҗәл дип эндәшсәләр, үпкәләмисезме?

– Бераз үпкә бар инде. Минем бит әйбәтрәк рольләрем бар иде, нишләптер аларын искә алмыйлар. Башта ук бу рольне биргәнгә куанмадым, Әлмәндәрне уйныйсым килгән иде. Әҗәл бит ул кансыз. Ләкин спектакльдә Әлмәндәр бар. Аның оптимизмы хәтта Әҗәлгә тәэсир итә һәм ул, әйдә аз гына түз инде дип, Әлмәндәрдән үлемне чигереп торырга рөхсәт бирүен сорый. Миңа рольнең шул ягы ошый. Гомумән, эшли башлагач, һәр рольне ярата башлыйсың. Яратмасаң, килеп чыкмый. Ә бу роль гаҗәп ул. Аңа, Әҗәл дус, дип эндәшәләр. Кем инде әҗәлгә дус дип эндәшсен татардан башка.

> Тискәре рольне әшәке итеп күрсәтәм дип, аны кара итеп уйнарга кирәкми. Һәрбер роль үзенә тартырга тиеш. Мәскәү сатира театры артисты Георгий Менглет башлыча тискәре образлар башкарды. Ул аларны шулкадәр әйбәт уйный, рәхәтләнеп сокланып утырасың. Тегенең әшәкелеге әйбәт! Артист сөекле булса, әшәкене уйнаганда, ә ул шулай булырга тиеш, синең бөтен дикъкатеңне били. Чөнки ул начар кешене уйнаганда, аның яхшы ягын эзли. Яхшы кешене уйнаганда, аның начар ягын карарга кирәк. Кеше беркайчан да бертөрле генә була алмый.

:: Яшь барган саен юмор хисе артамы, кимиме?

– Минеке кимеми. Юморсыз кеше – ярты кеше. Юморы булмаган кеше ул бөтен кеше түгел. Мин, мәсәлән, үземнән дә көлә алам. Үзеңнән көлә алмасаң, син юморист түгел. Бездә шундый юмористлар бар, үзенә бер сүз әйтсәң, җеннәре чыга. Көлә белергә кирәк. Сиңа төрттерәләр икән, кызык булса, көл! Аңа ачу килергә тиеш түгел. Ә кайвакыт көлке катыш сиңа киңәш тә килергә мөмкин. Колак сал.

:: Заманында Шамкай, Илсур Мортаза белән күрсәтелгән мәзәкләр өчен оят түгелме?

– Юк, мин ул эшем өчен үкенмим. Безнең билдән түбән юмор дигәне алай ук түбән түгел әле. Хәзер телевизорны ачсаң, менә анда чын мәгънәсендә түбән. Безнең алай булганы юк. Мин ул кассетаны рәхәтләнеп карый алам. Әмма үземдә берсе дә калмады, таратып бетердек. Кайчак интернетта кайберләре күренгәли.

:: Хәзер эстрадада юмор-сатира бармы?

– Бар ул, әммә... Мин үзем юмордан бигрәк, сатира яратам. Юморны бит аны,

ШӘРӘФИ СҮЗЕ

Кеше ялгышмыйча яши алмый, бу гомумән мөмкин түгел. Ялгышмыйм дисәң, күпкырлы булырга, әледән-әле кызыксынырга һәм китап укырга кирәк.

Югарыдагылар, дәрәҗәле кешеләр белән сөйләшкәндә, берсеннән дә уңайсызланмыйм. Бернинди комплексым да, кыенсынуым да юк, ә менә гади кешеләр белән саграк сөйләшергә тырышам, рәнҗетә күрмим дип борчылам.

Динне кыскан чорда мин мәчеткә йөрдем. Ни өченме? Нәкъ менә динне кысканга күрә. Дин сәясәт арбасына җигелергә тиеш түгел.

тешсез сатира, дип тә әйтәләр. Шуңа күрә Гамил Авзал, Фәнзаман Баттал әсәрләрен укыйм. Менә анда сатира ичмасам! Миңа сатира якынрак. Әмма аны бервакытта да яратмадылар.

:: Мәдәният тармагында бигрәк тә нәрсә өчен күңелегез әрни?

– Эстрада аяныч хәлдә. Мин кайбер концертлардан, карый алмыйча, чыгып китәм. Хәзер бит җиз иләктән үткәрү, сайлау юк. Элек худсовет бар иде. Радиога җыр биргәндә дә комиссия хәер-фатыйхасын алырга кирәк иде. Аның аша шәп әйберләр генә чыга һәм артистлар җырлыймы ул, сөйлиме – акча ала иде. Ә хәзер киресенчә: өч тиенгә ярамаган җырларын, үзләре акча биреп, телевидениегә чыгаралар. Дөньяга үзеңне шул дәрәҗәгә төшереп күрсәткәч, без нинди халык? Радиоларда да шул ук хәл. «Тәртип» радиосын яратып тыңлыйм, ә менә «Болгар» радиосы бик күңелгә ятмый. Ә бит безнең инструменталь әсәрләребез бик күп. Ренат Еникиев әсәрләрен тыңлап туймаслык! Александр Ключарев әсәрләре – чын җәүһәрләр. Ник шуларны бирмиләр? Халыкны бетерәбез бит. Халыкны тәрбияләргә кирәк, диләр. Мин гомер буе әйтәм: тәрбияләргә кирәкми, бозмаска кирәк. Без аның зәвыгын бозабыз.

Студент вакытта безне студиядә эшләгән рольләребез белән Татарстан авылларына гастрольләргә җибәрделәр. Мин, мәсәлән, Дон-Кихотны уйнадым. Авыл халкы чит ил классикасын, рус классикасын тын да алмый тыңлый. Хәзер тыңлатырсың син аларга. Аңа хәзер тозсыз әнә теге нәрсәләр кирәк. Мәзәк дип әйтергә тел әйләнми. Шуңа мин, тәрбияләмә, бозмыйк кына, дим. Без боздык. Бер бозгач, ул инде татлы әйберне кабул итә алмый.

:: Мәдәният министры итеп куйдылар ди, иң беренче нәрсәне үзгәртер идегез?

– Министр итеп куйсалар, эшли алмас идем. Рәшидә апа Җиһаншина директор урынбасары итеп чакырды, бармадым. Минем эш түгел ул. Киңәшче булсам, киңәш бирер идем. Олы-олы кешеләр белән сөйләшәм кайвакытта, укымышлы дип саналганнары да чын сәнгатьнең нәрсә икәнен аңлап бетерми икән. Кеше ничек бирә, шулай кабул итәләр. Артистлар арасында да үзләрен бөек дип санаучылар бар.

:: Сезгә «бөек» дип әйткәннәре бармы?

– Әйтәләр. Бер районга кайткач, сездә гел бөекләр инде, дидем. Ул як кешеләре үзләрен ярата торган чөнки. Шул якта миңа, безнең өчен син бөек, дигәннәре бар.

Минем бер нәрсәне әйтәсем килә. Картайгач, без дөрес яшәмәгәнбез, дигән фикергә килдем. Ни бирсәләр, шуны уйнап, гомер уздырдык. Безгә үзебез уйныйсы килгәнне уйныйсы булган. Кайвакыт сорап ала белергә дә кирәк. Алдан сөйли башлаган идем бит, авылларда уйнап йөрдек дип. Менә шул, бер авылда яныма бер егет керде. «Мин өченче авылда карыйм инде сезне. Черкасовтан да әйбәт сез», – ди. Авыл малае өченче тапкыр карый һәм Черкасовны белә! Мин менә шуңа сөендем. Юк, мин үземне Черкасов янәшәсенә куя алмыйм. Чөнки Черкасов – минем өчен кумир ул, бөтен яктан да. Халыкның бозылмаганына мисал буларак сөйләдем бу хәлне. Театрда менә шул рольне сорадым, әмма уйнатмадылар.

Дон Кихотны миллионга бер артист уйный ала. Ул – үзгә бер образ. Аңа психо-физик халәт туры килергә тиеш. Мин аны уйнарга, халык аны карап еларга тиеш иде. Ул бит инде, бер карасаң, җүләр, ләкин саф күңелле, хыялый.

Германиядә яшәүче дустым үзенең сценарием тәкъдим итеп карады, әле җитмәсә, доллар белән күп кенә акча тәкъдим итте, куйдырмадылар. Ул – Украинаның бөек артисты Богдан Ступка белән спектакль куеп, Америкага барып уйнаткан кеше. Нишлисең, булмады.

:: Театрны ташлар чиккә җиткән булдымы?

– Театрдан китеп торганым булды. Сәхнәдән кирәкмәгән сүз әйттем дә, чыгарып тордылар. Бер атнадан обкомга чакырып, син кайт инде, диделәр. Мин инде филармониягә эшкә кергән идем. Һич югы икенче сезонга кадәр аннан китмим, дидем. Алланың рәхмәте, әйбәт булды. Илһам белән (Шакиров. – **Ред.**) шактый дөнья гиздем. Таһир Якупов белән эшләдем. Рәхәтләнеп йөреп калдым. Эстрадага китсәм дә, эшли алыр идем.

Театрда Илһам концерты бара. Сәхнәгә чыгуым була, халык күтәрелеп кул чаба. Минем куылганны беләләр бит инде. Кайда да шул хәл. Габдулла Шамуков – акыллы кеше, тегеләргә әйткән, сез бит аны театрдан чыгарып, популярлыгын гына күтәрәсез, дигән. Мин инде театрның юк акчасына яшәп ятканчы, бераз акча эшләп алырга уйладым. Театрга 8 айдан соң гына кайттым.

:: Иң зур теләгегез нинди?

– Аны әйтергә ярамый.

:: Театр яшьләре – нинди алар?

– Әйбәт, рухи яктан көчле артистлар бар. Бигрәк тә егетләрдән күбесен үз итәм. Әйтә башласаң, берсен берсеннән аеру була, исемнәрен атамыйк.

> Татар – табигате белән артист. Безнең татардагы шикелле артист табигате башка халыкта юк. Репертуар гына булсын. Әгәр дә кемгәдер ияреп эшли башласак, театрның киләчәге юк. Татар театры үзенчәлекле булуы белән аерылып торды.

1957 елда Мәскәүдә Татарстан сәнгате декадасы булды. Анда безне, бу – артист театры, диделәр. Чөнки режиссер артистны басмый иде. Шуңа элекке артистлар барысы да асылташ булды. Аның уртача дигәне дә әйбәт, алар бер-берсеннән аерылып торалар иде. Хәзер барысы да бертөрлегә әйләнеп бара.

Бигрәк тә Мәскәүдә шушы хәл күзәтелә. Кино карасаң да, элеккеге артистлар юк инде. Гел үтереш турындагы фильмнарда уйнагач, хәтта артистлар да бандит кыяфәтле. Чөнки рухлары имгәнә, күзләрендә иман бетеп бара. Элеккеге артистлар андый түгел иде бит. Аларның карашы тирән, анда хис тә, миһербанлылык та ята иде. Күрәсең, болар хәзерге заманга ят хисләрдер.

:: Матбугат белән танышып барасызмы? Сезнеңчә, татар матбугаты нинди хәлдә?

– Матбугат белән элеккеге кебек кызыксынуым юк инде. Миңа язмаларның гайбәт дәрәҗәсенә төшүе дә ошап җитми. Кемнең баласы кемнән туган, кем кем белән кая барган – нәрсәгә кирәк ул? Артистлар турында язганда да, аларның тормышына артык тыкшынуны өнәп бетермим. Артистта серлелек калырга тиеш.

:: Үзеңне формада ничек тотарга?

– Камыр ризыкларын чама белән ашарга, хәрәкәттә булырга кирәк. Сезгә килгәнче паркта чаңгыда йөреп кердем әле.

:: Хатыныгызга ничек дәшәсез?

– Җаный дип дәшәм.

:: Хәләлегезгә яратам дип әйтәсезме?

– Юк, әйтмим. Яратканны үзең сизәсең аны. Ул да миңа яратам дип әйтми, үзем сизәм мин аны. Яратканны яратам дип әйтергә кирәкми. Нинди төчеләнеп тору ул?! Хәзер гел яратам дип торалар. Ләкин аларның «яратам»ында еш кына ярату да булмый.

:: Мәхәббәт бармы?

– Мәхәббәт бар. Ләкин хәзер бетеп бара. Бигрәк тә хатын-кызда әлеге хис саега. Хәзер хистән бигрәк матди як алга чыкты. Мин үзем яратмаган кеше белән яши алмыйм. Яратмаган кешенең бөтен хәрәкәте ачу китерә аның.

Гашыйк булганнарым маржалар иде. Татар булуым белән, алар бик теләсәләр дә, кушыла алмадылар. Яшьлектә хис белән яшисең әле ул, картлыкта икең ике якка тарта башласа, нишләрсең? Ә шулай булачак бит ул.

> Бер нәрсәне әйтәсем килә. Дөньяда иң яратмаган нәрсәм – нәфес. Хәзер нәфес патша бөтен дөньяга. Нәфес аркасында җир җитми, низаглар чыга. Нәфесне нәҗестән бер хәреф кенә аерып тора. Һәр икесендә дә бу хәрефләр канатлы. Нәфестә «ф» хәрефе йомылып тора, нәҗестә «җ» ачылган. Дөньяны менә шушы әшәке басты.

ВИДЕО – VATANTAT.RU САЙТЫНДА



Шигърият

Гамил АВЗАЛ

ТУГАН АВЫЛ БЕЛӘН САУБУЛЛАШУ

Сау бул инде, михнәт чиккән дөнья,
Суык җилле, юеш, караңгы көз,
Бәке тишеп кер чайкаган елга,
Күченәбез.

Бала чактан таныш якын-тирә,
Газиз булып, күңелләргә инде,
Ялантәпи баскан яшел чирәм,
Сау бул инде.

Сау бул инде, ялсыз, сәгатьсез эш,
Җитез килен булып баскан тупса,
Зәңгәр генә, җырлы, йолдызлы кич,
Кара мунча.

Кеше булып тәпи баскан төшкә
Язлар килде, сандугачлар килде.
Ата-баба сулар эчкән чишмә,
Сау бул инде.

Сау бул инде, шыгырдавык капка,
Шыгырдама җилләр искән чакта!
Тәрәзәгә кадакланган такта
Туган якта.

Хәерле юл теләп фатиха бир,
Биттән сыйпа, туган яклар җиле!
Машиналар изгән кадерсез җир,
Сау бул инде.

Сау булыгыз, зират каеннары,
Әби-бабай сеңгән изге туфрак,
Йокымсырап яткан кайгылары,
Җирдә сыкрап.

Газап чигә-чигә түгелгән тир
Бу җирләргә яңгыр булып килде,
Бушка эшләп җилкә чиләнгән җир,
Сау бул инде!

СҮЗ

Сүз әйтергә тәвәккәллек кирәк,
Сүз йөрәккә ялкын үткәрә;
Сүз киптерә, төп башына терәп,
Сүз меңнәрне яуга күтәрә.

Сүз зиһенне кайрый кайрак кебек,
Сүз сафларны илпи корычтай;
Сүз көрәшкә чыга байрак кебек,
Сүз дошманны кисә кылычтай.

* * *

Безнең тарих озын, ускән кызым,
Борыла-борыла аккан сулар кебек,
Һәр борылышта берәр бабаң торган,
Бу камышлар шаулый шулар кебек.

Бу басуда әбиең урак урган,
Бу болында бабаң печән чапкан,
Бу урманнар һаман шаулап торган,
Борылып-борылып сулар аккан.

Сандугачлар сайрый сиңа карап,
Ай елмаеп тора зәңгәр кичен,
Җилләр исә чәчләреңне тарап,
Ак болытлар ага синең өчен.

Безнең гомер озын, ускән улым,
Урман буйларында күксел рәшә,
Әнә сиңа мең чәчәкле болын,
Һәр бөҗәккә абый булып яшә!

Башларыннан сыйпа арышларны,
Башларыннан сыйпа куакларны,
Кабатлама безнең ялгышларны,
Кабатлама безнең гөнаһларны!

23 февраль, Ватанны саклаучылар көнендә, «ТНВ» һәм «ТНВ-Планета» телеканалларында «Барысы да – Җиңү өчен!» бөтенроссия акциясе кысасында телевизион марафон узачак.

Марафонның башлап йөрүчесе – Гомумроссия халык фронтының Татарстан Республикасындагы төбәк бүлеге. Теләге булган һәркем махсус хәрби операциядә катнашучыларга матди ярдәм күрсәтә ала. Моның өчен экранда күрсәтелгән QR-кодны кулланырга кирәк була. Җыелган ярдәм Татарстаннан мобилизацияләнгәннәргә һәм үз теләге белән баручыларга тапшырылачак.

Марафон 23 нче февральдә көндезге 10да башлана. Фронт сызыгындагы сугышчыларга ярдәм итик!



Сканворд җаваплары

Горизонталь: бавырсак, Макрон, Ом, Зилант, Такташ, ки, әнә, имам, Корса, ау, ант, ВИА, ачкыч, Ла, ал, Празат, иш, ро, олы, хәләл, ола, күгәрчен.

Вертикаль: Бәдретдинов, Апас, Иа, Хек, Алмачуар, тәм, зоолог, Рамазан, Лалә, ишәк, Чаткылар, Кол, кармак, Алла, Ниссан, Али, янут, аут, Шәкүр.

Беләсең килсә...

1 «Әгәр сез канатсыз тугансыз икән, һич югы аларның үсүенә комачауламагыз», – дип кем әйткән?
а) Коко Шанель;
б) Фаина Раневская;
в) Әлфия Авзалова.

2 Кеше ничә яшькә җиткәч, дәүләт аны озак яшәүчеләр категориясенә кертә башлый?
а) 80;
б) 90;
в) 100.

3 Дөньяда иң зур җанвар:
а) зәңгәр кит;
б) кашалот;
в) Африка филе.

4 Галимҗан Баруди кайда үлгән?
а) Бохарада;
б) Казанда;
в) Мәскәүдә.

Җаваплар: 1. а); 2. б); 3. а); 4. в).

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15277 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 224

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+